## Равил Сәйфетдиновның педагогикага һәм мәктәп тормышына кагылышлы мәкаләләре

### Гали авылында

Университетета укыган елларымда мин журналист булып эшләргә хыялланып яшәдем. Инде ул хыялым өлешчә чынга да ашкан иде: “Татарстан яшьләре” газетасы мине штаттан тыш хәбәрчесе итте һәм мин, бик мавыгып китеп, күп кенә мәкаләләр язып бастырдым. Университетта безне укытучылыкка да әзерләделәр. Педагогик практиканы да уңышлы үттем. Бу – 1960 нчы елның февраль-март айлары иде. Ул чакта Казанда 35 нче һәм 89 нчы мәктәпләрдә барлык фәннәрне дә татарча укыталар иде. Мине 89 нчы мәктәпкә билгеләделәр. Бу мәктәп телевидение бинасыннан ерак булмаган урында булып, каршысындагы бакчада Галимҗан Ибраһимов бюсты тора иде. Телевидение дигәннән, ул нәкъ менә 1960 нчы елда ачылып, без студиядә Нәкый Исәнбәтнең “Җәлил” трагедиясен башкарып, ул еллар өчен үзенә күрә бер могҗиза күрсәткән идек. Көчле прожекторлар яктысы астында гомердә булмаганча тирләп-пешеп беткән идек. Безнең педпрактика белән кафедрадагы яп-яшь укытучы Фуат Ганиев җитәкчелек итте. Гаять таләпчән һәм искиткеч гадел бу кеше, бөтен көчен куеп, безне педагог булырга өйрәтте (ул зур дәрәҗәдәге галим, профессор, академик буларак бөтен илгә танылды). Без татар теле һәм әдәбияты укытучысы (әллә ничә медаль, орден кавалеры, РСФСРның атказанган укытучысы, мәгариф отличнигы) Фатыйма апа Җәләлиеваның бик күп дәресләрен карап, хәйраннар калып утырдык һәм аннары аның күп дәресләрен үзебез укытып, ул безнең һәр сүзебезне, һәр хәрәкәтебезне энә күзеннән үткәреп утырды. Миңа бөтен сәләтемне куеп тырышырга туры килде, чөнки Фатыйма апа яшь чагында безнең Мулла Иле мәктәбендә укыткан һәм бер ел директор да булып торган. Аның ире Вазыйх абый Надриев та бездә укыткан һәм сугыш башлануга фронтка киткән. Исән-сау әйләнеп кайткач, алар өйләнешкәннәр һәм менә шул мәктәпкә урнашканнар. Озакламый Вазыйх абыйны мәктәп директоры итеп куйганнар.

Фатыйма апа минем әти-әниемне дә яхшы белә икән. “Мулла Иле – минем бәхетем кояшы ул, мине Мулла Иле кеше итте”, – дия-дия, мине гел игътибар үзәгендә тотты. Аннары гомере буе минем белән тыгыз элемтәдә яшәде. Инде мин Мулла Илендә укытканда, ничә мәртәбә үзебез укытучыларны аның мәктәбенә тәҗрибә җыярга алып бардым. Ә 1978 елда, әлеге татар мәктәбе ябылгач, Фатыйма апа үзенең барлык хәзинәсен миңа төяп җибәрде. “Милләтебез чәчәк атып бетте”, – дип тыела алмыйча елады ул.

Практика вакытында мин күрсәткән ачык дәресләр югары бәя алдылар. Фатыйма апаның сүзләре истә калды: “Иң мөһиме: татар телен, аның әдәбиятын фанатик ярату белән яратасың. Дәресләрне җәелеп китеп, рухланып, илһамланып үткәрәсең. Чын йөрәктән, чын күңелдән. Күрсәтү өчен түгел. Дәрестә син материалны шундый мавыгу белән бирәсең, вакыт-вакыт үзеңнең кайдалыгыңны да онытып җибәрәсең, хәтта укучыларны да күрми башлыйсың”.

Газета редакциясендә эшләү теләгем чәлпәрәмә килеп җимерелде: катгый рәвештә мәҗбүр итеп, мине Куйбышев өлкәсендәге Гали авылы урта мәктәбенә укытучы итеп җибәрделәр. Мине аңлаучы табылмады, югыйсә үзебез авыл мәктәбендә дә урын бар иде, район газетасы редакциясе дә мине эшкә алырга риза иде. Аннары минем гаилә хәлем гаять авыр иде: әти сугышта һәлак булган, авылда йортыбыз тәмам искереп беткән, өч улын сугыш йоткан әбием сукыраеп утыра, әни көн-төн колхоз эшендә эшли.

Беркайда да хаклык табалмыйча җаным кыйналган килеш, мин август ахырында, әбием белән әнине хафага салып, Гали авылына китеп бардым. Башта Албабадан Куйбышевка кадәр, аннары Куйбышевтан Похвистнево дигән шәһәргә чаклы поездларда барып, Похвистневодан Гали авылына автобус белән килдем. Шоссе авылның үзәк урамы буйлап Камышлыга китеп бара икән. Мәктәп авылның нәкъ үзәк бер җирендә икән. Мин шул урында төшеп калдым.

Менә ул Гали мәктәбе. Әле яңа гына төзелеп беткән бер типовой таш мәктәп. Әлбәттә, ул барлык укучыларны да сыйдырырлык түгел, шуңа күрә аның янәшәсендәге аерым-аерым утыручы агач биналарда да укыталар икән. Директор Мәрьям Гәрәевна Морзаханова мине көтеп утыра иде. Мин аңа үземнең хәлемне аңлаттым. “Ике елга түз инде, аның каравы йөзең ак була, репутацияң югары була”, – дигән сүзләр белән үгетләде. Кайсы классларда ничә сәгать укытачагым белән таныштырды. Аннары, мәктәптән ерак булмаган бер йортка алып барып, мине бер әби карамагына тапшырды. Күңел җирси. Менә кайда вакытымны заяга әрәм итеп ятам. Буш вакыт юкка уза. Үзебез авылда укытсам, йорт-җирне рәтләр идем, әби-әни күрәләтә зар-интизар хәлдә бит.

Укытучылар минем хәлне аңладылар, һәрберсе үзләренчә юатты, ярдәм итте. Минем квартира күршесендә яшәүче Мидхәд абый белән Роза апа, икесе дә укытучылар булып, мине гел мунчага чакырып тордылар. Суфия апа Кабаева белән Сәгыйть абый Садриев, Лотфулла абый Сафиуллин белән Халидә апа Насретдинова, Панна Ивановна Алексеева, Ядкяр абый Гәрәев, Суфия апа Курамшина, Фәүзия апа Гайнанова, Гөлйөзем Ишкинәева, Наилә Ибәтуллина – һәрбересе дә минем хәтеремдә иң изге күңелле укытучылар булып калды. Гали авылындагы Латыйповлар династиясе турында аерым әйтәсем килә. Бөтен гомерен Гали авылы халкы тормышын

яхшыртуга багышлаган Газиз абый Латыйпов мине көрәшче булып яшәргә өйрәтте. Аның кызы Ленина Латыйпова, мәктәпнең иң талантлы педагогы буларак, мине укыту серләренә өйрәтте. Латыйповлар династиясе вәкиле Үзбәк Фатыйхович Хәсәнов исә 1968-1989 нчы елларда безнең Яшел Үзән районында мәгариф бүлеге мөдире булып эшләде. Гали авылы мәктәбе укытучыларының күбесе күршедәге Камышлы педучилищесын бетерүчеләр иде. Аларның берсе Илгиз Камалиев Яшел Үзән РОНОсында методист булып эшләде. Гали авылы китапханәсе гаять бай иде. РСФСРның атказанган китапханәчесе Әлфия апа Моратова мине бөтен китаплар белән тәэмин итеп торды. Авылда күптәннән бирле бик көчле драмтүгәрәк эшләп килә иде. Мин дә күп спектакльләрдә катнаштым. Тажи Гыйззәтнең “Төнге сигнал” , “Изге әманәт” пъесаларын Куйбышев (Самара) шәһәренә дә барып куйдык. 1962 нче елда укытучы Ядкяр абый Гәрәев мәктәптә туган якны өйрәнү музеен ачты.

Хәзер Гали авылының даны бөтен Россиягә билгеле. Анда илкүләм Сабантуйлар үткәрелә. Гали халкының бүгенге тормыштагы казанышлары әледән-әле телевизорда күрсәтелә. Шуларны карап утыру бик рәхәт: буйдан-буйга сузылып киткән мәһабәт таулар, шулар астында тын гына агып яткан елга, шул елга үзәне буйлап җәелеп сузылган киң матур туры урамнар... 2010 нчы елда Гали авылының 400 еллык юбилеен зурлап үткәрделәр. Шул уңай белән чыккан зиннәтле китапны миңа бүләк итеп җибәрделәр. 2011

**“Тукайда кунакта”**

Башлангыч классларда уку дәресләрен рәсем сәнгате белән, музыка сәнгате белән тыгыз бәйләнештә үткәреп, әдәби әсәрләрдән килеп чыга торган идеяләрне төрле уеннар ярдәмендә укучыларга җиткерү алымнарын куллануга аеруча зур игътибар бирик. Мәсәлән, укытучының традицион булмаган бер дәресеннән мисал. Тема: “Габдулла Тукайда кунакта”. Дәрес “Туган тел” көен тыңлау белән башлана. Класс алдына эленгән төсле рәсемнәрне – иллюстрацияләрне карыйлар. Һәр рәсем бер өй форматы уртасына урнаштырылган. Бу рәсемнәр Тукайның кайсы әсәренә туры киләләр – укучылар шуларны табып чыгалар. Тукай бу әсәрләрдә нәрсәгә өйрәтә? Укытучы төсле этикеткалар күрсәтә: дөреслекне ялгыштан аера бел, урлашма, чагыштыра бел, тереклек дөньясына мәрхәмәтле бул, мактанма, хайваннарны ярат, тапкыр бул, туган телеңне ярат, кечкенәдән эшләргә өйрән, югалып калма – берәр җаен тап. Балалар шушы сүзләрне (фикер-идеяләрне) өй-рәсем-шигырь асларына урнаштыралар. Укытучы, шундый алымнар кулланып, Тукайның “Каз”, “Су анасы”, “Кыш йокысы”, “Бала белән күбәләк”, “Ташбака белән куян”, “Гали белән кәҗә”, “Шүрәле”, “Туган тел”, “Малай белән маэмай”, “Кәҗә белән сарык” әсәрләреннән килеп чыга торган

идеяләрне укучыларның күңеленә сеңдерә, бер үк вакытта укучыларның белемнәрен гомумиләштерә һәм билгеле бер системага сала. Укытучы уку дәресләрендә балалардан “Тукайга хат” дигән мөстәкыйль-иҗади язма эш тә эшләтә.
2000

**Тамырлар нык булсын**

***“Мулла Иле дигән авылдан син...”***

*Илдар Юзеев*

Үткәне булмаганның киләчәге юк, ди халык. Бүгенгенең кадерен белү өчен, үткәнебезне белергә һәм истәлекләрен кадерләп сакларга кирәк. Минем туган авылымның тарихы ерак гасырларга барып тоташа: ул 1240 нчы елларда нигезләнгән. 1990 нчы елда аның 750 еллыгын зурлап билгеләп үткән идек. Авылда мәгариф эше дә бик борынгыдан башланып киткән. Авылга нигез салучыларның берсе – Теләш, галим кеше булып, Мулла Илендә мәдрәсә салган һәм дәрес әйткән. Аның оныгы Ишмөхәммәт мулла күп еллар буе мәдрәсәдә шәкертләр укыткан.

Татар милли азатлыгы хәрәкәтенең күренекле каһарманнары – авылдашларыбыз Баһаветдин һәм аның улы Гайнан Вәисовлар авылыбыз мәдрәсәсендә белем алганнар (XIX гасырда).

XX гасыр башында, Зөя өязендә беренче булып, башлангыч рус-татар мәктәбе ачылган. Аның беренче укытучысы авылыбыз кешесе Казанда укытучылар мәктәбендә укып кайткан Гыйззәтулла Галиәкбәров була. Ул 1910 елның җәендә Мулла Иленә кунакка бөек шагыйребез Г.Тукайны алып кайта. Шагыйрьнең бу юллары шул тәэсирләрдән язылгандыр дип уйлыйм:

*Читтәге бик күп өяздә,*
*Күр, авыллар яктыра,*
*Пар, тату йолдыз кеби*
*Школ белән мәктәп тора...*

1918-1930 нчы елларда мәктәптә Зөя укытучылар курсларын тәмамлаган укытучылар укыта. Сәет Индиков бу елларда мәктәп мөдире булып эшли. Аның тырышлыгы белән 1923 нче елда, алпавыт Пётр Ярахтинның йортларын сүтеп, иркен мәктәп бинасы өлгертәләр. Укытучыларның шатлыгы эченә сыймый. Ләкин бу мәктәп бинасында ике генә атна укытып калалар: дошманнар аны ут төртеп яндыралар. Кара күмерләр өстенә Сәетнең күз яшьләре тама.

Ниһаять, 1928 нче елда шактый зур мәктәп бинасы җиткерелә, һәм дүрт еллык мәҗбүри уку кертелә. Аннары җидееллык мәктәп бинасы төзүгә әзерлек башлана. Колхоз атлары белән Иделдән бүрәнә ташыйлар, һәм менә 1935 нче елның җәендә бөтен уңайлыклары булган ике катлы зур типовой мәктәп бинасы төзелеп бетә. 1936 нчы елда җидееллык мәктәпнең беренче чыгарылышы була. Шул чыгарылыш укучысы Вәгыйзә Кәлимуллина, соңыннан үзе укытучы

булып, татар теле укытуда зур казанышларга иреште (минем укытучым һәм остазым).

Ватан сугышы елларында укулар бер генә көнгә дә өзелеп тормады. Ул елларда мин балалар бакчасына йөрдем. Сугыштан соң, 1946 нчы елда, мәктәпкә беренче сыйныфка укырга килдем. Үзем генә килдем, өйдән озатып килүче булмады: әти сугышта үлеп калган, әни колхозда тәүлеклек эштән кайтмаган, әби сугышта өч баласын югалту хәсрәтеннән өйдә авырып ята. Сыйныф җитәкчеләрем Фаика Балтановага (I – IV), Роза Тимершинага (V – VII) бик зур рәхмәт. Мине башымнан сыйпап үстерделәр, кыерсытуларга юл куймадылар.

Мин укыган елларда, мәктәп директорлары булып, утлар-сулар кичеп, сугыштан яраланып кайткан фронтовиклар Габдулла Сәмигуллин, Сибгать Манеков, Сәлим Абдуллин һәм Хәйретдин Сәлаховлар эшләделәр. Мин аларның дәресләрендә бик тәэсирләнеп утыра идем: алар фронт истәлекләрен сөйләгәндә, һәлак булган әтиемне күргән кебек була идем.

1963 нче елда туган мәктәбемә укытучы булып эшкә кайттым. Бөтенләйгә, гомерлеккә, һәм биредә менә 40 елдан артык берөзлексез эшләп килдем. Рухланып, ялкынланып, иҗат итеп. Алтмыштан артык мәкаләм республика газет-журналларында басылды. Үземнең укытучыларым белән бергә эшләү күңелле булды. 1968-70 нче елларда – завуч, 1971-2000 нче елларда бертоташтан мәктәп директоры булып эшләдем.

1974 нче елда, бер җәй эчендә, җылы тормый торган, кыйшайган ике катлы иске мәктәпне сүтеп, бер катлы итеп яңа бина кордык. Шартлар яхшырды. 1975 нче елдан башлап Казан укытучылар белемен күтәрү институтының база мәктәбе булдык. Бездә республика күләмендәге бик күп семинарлар үткәрелде. 1935-85 нче елларда тулы булмаган урта мәктәпне 1300 укучы тәмамлады. Кичке мәктәптә укытып, 170 укучыга аттестат тапшырдык.

1985 нче елда мәктәп урта мәктәп итеп үзгәртелде. Ә 1986 нчы елда колхоз рәисе Э.С.Гобәйдуллин тырышлыгы белән төзелгән урта мәктәп бинасында укый башладык. 1987-2000 нче елларда урта мәктәпне 210 укучы бетерде, шуларның 20 се медаль белән чыкты. 60 укучы вузларга керде. Район олимпиадаларында татар теле һәм рус теле буенча безнең укучылар күп елларда җиңүчеләр булдылар. 1985 нче елдан 6 яшьтән укытуга күчтек. Мәктәп коллективы "Ел мәктәбе исемен яулады (1994). Татар теле кабинеты республика смотрында икенче урынны алды (1989). Укучылар производство бригадаларының республика смотрында катнашты: Мәгариф министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләндек (1988). 1968-2000 нче елларда һәр елны 12 гектар мәйданда кишер, чөгендер, суган үстердек. Типовой теплицабыз бөтен авылны кышларын яшел суган һ.б. белән тәэмин итеп килде.

Вузда укучы студентларыбыз мәктәп һәм авылның тарихын өйрәнүгә житди өлеш керттеләр. "Профессор Г.Ф.Саттаровның фәнни-педагогик эшчәнлеге", "Тарихчы галим Хәйретдин Гыймадиның фәнни эшчәнлеге", "Мулла Иле тарихы" дигән темаларга диплом эшләре яздылар.

Мулла Иле мәктәбе – чын безнеңчә милли мәктәп. Безнең горурлыгыбыз булган профессор Г.Ф.Саттаров мәктәптә сугыш елларында фәкать бишкә генә укыган. Безнең мәктәпне бетергән 31 укучы филология факультетын тәмамлады. Бүген мәктәптә 23 укытучы, шуларның 2 се – югары, 13 е икенче категорияле.

Быелгы уку елында мәктәп җитәкчелегенә яшьләр килде. Шәкертләрем Фәнис Дамир улы Кәбиров – директор, Илдар Галимҗан улы Сәләхиев тәрбия эше буенча урынбасар булып эшли башладылар. Уку эшләре буенча урынбасар Рәмзия Хәбибулла кызы Шәкүрова күркәм эшләр белән сөендерә.

Мәктәп – ышанычлы кулларда. Ул, белем диңгезендәге олы кораб кебек, гел алга карап юл ярсын.
*2001*

**«Язгы аҗаган» романы буенча конференция-диспут**

Укучыларның мөстәкыйльлеген, иҗади активлыгын үстерүдә әдәби әсәрләр буенча конференцияләр һәм диспутлар үткәрүнең роле гаять зур. Шуңа күрә бу эшкә җитди әһәмият бирәбез. Соңгы бер-ике елда гына да Ф. Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала», А. Гыйләҗевның «Җомга көн, кич белән», Ә. Давыдовның «Муса абый» повестьлары, Н. Островскийның «Корыч ничек чыныкты», М. Хәсәновның «Язгы аҗаган» романнары һәм башка әсәрләр буенча шундый конференция-диспутлар оештырдык.

Биредә мин М. Хәсәновның Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булган «Язгы аҗаган» романы буенча үткәрелгән конференциягә тукталмакчы булам.

Башта ук шуны әйтик, без әсәрне сайлап алуга нык игътибар итәбез: әсәр яратып укыла торган, идея-эчтәлеге ягыннан укучыларда югары әхлак сыйфатлары тәрбияләрлек, художество эшләнеше югары булсын. «Язгы аҗаган» – әнә шундый әсәр. Конференция, диспутлар үткәргәндә, без укучыларның яшь үзенчәлекләрен дә искә алабыз. Мәсәлән, Дж. Лондонның «Яшәү теләге» хикәясе буенча конференцияне IV-VI класс укучылары белән үткәрсәк, «Язгы аҗаган» кебек җитди әсәрләрне VII-X классларга тәкъдим итәбез.

Конференция-диспут үткәреләчәге турында укучыларга өч ай алдан белдерү ясадык (чөнки әсәр зур күләмле, аны укучылар укып чыгарга өлгерергә тиеш).

Бу эш әдәбият укытучысы җитәкчелегендә оештырыла. Аңа мәктәп һәм авыл китапханәләре хезмәткәрләре дә ярдәм итә. Алар балаларны китаплар белән тәэмин итәләр, кирәк булса, әлеге китап районгадагы башка китапханәләрдән дә алып торыла, әсәрнең «Казан

утлары» журналында басылган варианты да файдаланыла. Балаларның әсәрне ничек укуына контроль укучылар үзидарәсе аркылы тормышка ашырыла. Әсәрнең аеруча тәэсирле бүлекләрен аерым классларда дәрестән тыш вакытларда кычкырып укулар да оештырыла. Укучыларның индивидуаль үзенчәлекләре дә исәпкә алына: бу зур күләмле романны укып чыгарга әле көче җитми торган балаларга әсәрнең аерым бүлекләрен тәкъдим иттек. Аннары әзерләнү өчен сораулык язып элдек:

1. Ни өчен М. Хәсәнов бу әсәрен «Язгы аҗаган» дип атаган?
2. Романның сюжет нигезендә нинди вакыйгалар ята?
3. Аның композицион төзелешендә нинди үзенчәлекләр бар?
4. Революция каһарманы Иргалинең язмышы нигә фаҗигале була? Без аны кулак дип атый алабызмы? Ул тормышның төп максатын нәрсәдә күрә?
5. Кем ул Халәп?
6. Ватан сугышында зур батырлыклар күрсәткән Газиның тормышы нигә фаҗигале була? Аның Гөлүсәгә мәхәббәте үкенечле булуының сәбәбе нәрсәдә? Аның тормышында Кремнев нинди роль уйный?
7. Гөлүсәнең кайсы яклары укучыны сокландыра?
8. Себер егете Лачында нинди күркәм сыйфатлар күрәсез?
9. Иргали, Гази, Гөлүсәләргә нинди уртак сыйфатлар хас?
10. Әсәрнең әһәмияте нәрсәдә?

Аерым укучыларга индивидуаль биремнәр тәкъдим ителде, консультацияләр үткәрелде.

Конференция-диспут үткәрү көненә мәктәп залын тиешенчә җиһазладык: стенага язучының портретын, тормыш һәм иҗат юлын чагылдырган әдәби бюллетень, китап турындагы афоризмнардан плакатлар элеп куйдык, авторның әсәрләреннән («Яңа горизонт», «Урман шаулый», «Саф җилләр», «Юллар, юллар», «Саумы, кояш!» «Шөгеревләр», «Без 6А дан», «Динозаврлар өнендә», «Шайтан малае» һ. б.), «Язгы аҗаган» әсәренә карата газета-журналларда чыккан рецензияләрдән (А. Гыйлаҗев. Куаныч китергән китап. «Социалистик Татарстан», 19 декабрь, 1987 ел; Р. Вәлиев. Үз бәхетен тапкан әдип. «Яшь ленинчы», 20 декабрь, 1987 ел; Р. Сәйфетдинов. «Язгы аҗаган», «Идел ягы» газетасы (Зеленодольск районы газетасы), 21 декабрь, 1986 ел) күргәзмә оештырдык.

Конференция-диспутка сугыш һәм хезмәт ветераннарын, алдынгы колхозчыларны, ата-аналарны, совет, партия, колхоз җитәкчеләрен дә чакырдык. Конференция-диспутны, әдәбият укытучысы буларак, үзем алып бардым. Романны, әлбәттә, үзем бик игътибар белән укып чыккан, дәфтәремә романдагы геройларның исемнәрен һәм үзара бәйләнешләрен теркәп, вакыйгаларның схематик хронологиясен дә ясап һәм бик кирәкле өзекләрнең кайсы биттә икәнлеген билгеләп куйган, аеруча хикмәтле юлларын, афоризмнарны язып алган идем. Сүзне язучының үзе турында

кыскача белешмә бирү белән махсус әзерләнеп килгән укучы башлап җибәрде. Ул бигрәк тә авторның якташыбыз булуына, аның Зеленодольск шәһәрендә яшәвенә басым ясады. Аннары укытучы «Язгы аҗаган» романының язылу тарихын аңлатты, шуннан соң алдан ук тәкъдим ителгән сораулар буенча сөйләүләргә керешелде.

Ни өчен язучы әсәрен «Язгы аҗаган» дип атаган? дигән сорауга түбәндәге фикерләр әйтелә:

Аҗаган – табигатьнең серле бер күренеше. Мәгълүм булганча, аҗаган җәй ахырына таба төннәрен күзәтелә. Мәхмүт Хәсәнов үзенең әсәрен, әнә шул күренешкә бәйләп, «Язгы аҗаган» дип атаган. Әсәрнең төп геройларыннан берсе булган Гази яз башында күк йөзендә аҗаган балкышын күргән. Татар халык иҗатында исә борынгыдан шундый риваять яшәп килә: «Язгы аҗаган күргән кешене гомер буе ачы язмыш, фаҗигале хәлләр эзәрлекләр, тормышы тоташтан зар-интизарлы булыр, имеш». Автор әлеге әйтемне романга эпиграф итеп куйган. Язгы аҗаган образы әсәрдә поэтик образ булып тора. Ул – әсәрдәге геройларның фаҗигале, әмма шул ук вакытта якты язмышларын аңларга ярдәм итә. Бу риваять шуңа күрә нинди дер бер ырым буларак кабул ителми. Автор безне, укучыларны, алда булачак катлаулы язмышларны кабул итәргә әзерли, әсәрнең халыкчан моңын тудыра. Гази күңелендә аҗаган турында халык җырлары тибрәнә:

Арыш башак кыскан чакта
Уйный, диләр, аҗаган.
Аҗаган яктырып китә,
Күңелләрне шомландырып,
Әллә кемнәр искә төшә,
Сискәндереп, уйландырып.

Сюжет, композициягә кагылышлы сорауларга җавап итеп укучылар романдагы вакыйгаларның беренче империалистик сугыш елларыннан алып безнең көннәргә кадәр булган зур бер чорны үз эченә алуын әйтәләр. Әсәрдә төп ике сюжет сызыгы булуын билгеләп үтәләр: беренчесе – Иргали образы, икенчесе – Гази образы белән бәйләнешле вакыйгалар. Әсәрнең композицион төзелеше гаять кызыклы, үзенчәлекле.. (Шуңа күрә дә романны укыганда кызыксыну артканнан арта бара.) Роман җиде зур бүлектән, ягъни «җиде көн»нән тора. Җиде көн – бу журналист Фәйзинең Кама буйларындагы нефть ятмаларын тикшерү өчен Мәскәүдән килгән комиссия составында командировкада үткәргән көннәре. Биредә тарих Фәйзи образы аша бүгенге көн белән килеп бәйләнә.

Иргали образы сораулар буенча чыгышларда түбәндәгечә ачыкланды.

Әсәрдәге вакыйгалар Иргали образы белән тыгыз бәйләнгән. Иргали – катлаулы язмышлы кеше. Аның яшьлеге давыллы елларга туры килә. Өйләнү белән, аны империалистик сугышка алалар. Революцияне ул окопта каршылый. Бернинди икеләнүсез Кызыл

Армиягә язылa. Гражданнар сугышында катнаша, зур батырлыклар күрсәтә. Ләкин нигә соң революция каһарманы Иргалинең язмышы фаҗигаләр белән тулы була? Ул 1922 елда туган авылына әйләнеп кайтканда, әнисе ачлыктан үлгән, хатыны исә Иргали үзе фронтта чакта туган Гөлүсә исемле кызы белән бергә авылны ташлап киткән, нигез тузган була. Корыч ихтыярлы Иргали шушы коточкыч хәлләр алдында бөгелеп төшми. Аңардагы кыюлык, тәвәккәллек, ирлек булмастайны булдыра. Ул дуслары ярдәмендә атлы була, йорт-җирен торгыза. Кыскасы, ике куллап җиргә ябыша. Ул гади игенче генә түгел, ә новатор. Сортлы орлык кына чәчә, җирне фән кушканча ашлый. Терлекләргә азыкны үлчәп, санап ашата. Иргали хезмәтне яшәү чыганагы итеп аңлый.

Кем ул Халәп? дигән сорау буенча чыгыш ясауны бер укучыга алдан ук биреп куйган идек. Әлеге образга ул шактый киң характеристика бирде: Халәп авылда ата ялкау кеше була, кулыннан бер эш килми. Үзенең ярлылыгы белән мактана. Ярлы катлау вәкиле булудан файдаланып, партиягә керә. Партия исемен калкан итеп, үзенең ялкаулыгын яшерергә җай таба. Ячейканы үз кулына ала. Халәп Иргалинең партия члены булмавында начарлык күрә. Иргалинең тормышын яхшырта баруы аңа ошамый. Нәтиҗәдә, Иргалигә «кулак» дигән исем тагыла, аның һәр адымын күзәтә башлыйлар. Кулаклар исә моннан үзләренчә файдаланалар: авыл хәбәрчесен үтереп, гәүдәсен Иргалинең коймасы янына илтеп ташлыйлар. Шуннан Иргалигә коточкыч яла ягыла, аны гаиләсе белән бергә Себертә озаталар.

Укучы чыгышыннан соң укытучы түбәндәгеләрне өсти: торгынлык елларында Халәп шикелле демагоглар тел тегермәннәрен яхшы әйләндерделәр, бары тик карьера өчен генә партиягә үрмәләп, үзләренең булдыксызлыкларын партия исеме белән каплап калырга тырышучылар да аз булмады.

Иргали образына карата укучылар тагын шундый фикерләр әйтәләр: Иргали тормышының төп максатын Ватанга турылыклы хезмәт итүдә күрә. Гаять авыр язмыш сынавын чын ирләрчә кичерә: кешелеген югалтмый, горур һәм көчле рухлы, намуслы булып кала, армый-талмый хезмәт итә. Иргали тайга урманнарында да кеше булып кала. Иргалинең олылыгы – хезмәтендә. Нинди генә эшкә тотынмасын, ул аны үрнәк булырлык итеп башкара. Бәхетне эзләп түгел, эшләп таба. Язучы Иргали образы аркылы «дөреслек җиңеп чыга, дөреслек өчен көрәшергә кирәк, баш имәскә, бирешмәскә кирәк» дигән идеяне үткәрә. Озак еллардан соң, үтерүче табылып, Иргалинең нахакка гаепләнүе билгеле була. Иргали барыбер Себердә кала. Үзенең эше белән кешеләрне хәйран калдыра. Фидакарь хезмәте өчен орденнар белән бүләкләнә, депутат итеп сайлана.

Гази образын укучылар түбәндәгечә билгеләп үттеләр: Газиның язмышы да күп ягы белән Иргалинекенә охшаган. Аның әтисен кулаклар үтерә. Кулакларга каршы көрәшеп үсә Гази. Ул яшь чагында Иргалинең кызы Гөлүсәне өзелеп ярата. Ләкин аның бу мәхәббәте үкенечле булып чыга. Газине кулак кызы белән йөрисең дип котырталар. Менә шушы чакта Газида ихтыяр көче җитеп бетми. Ул сөеклесе Гөлүсәне яклап авыз ачмый.

Ә аннары Гөлүсә, семьялары белән бергә, Себергә сөрелә. Гөлүсә Гази өчен гомерлеккә төзәлмәслек йөрәк ярасы булып кала. Гөлүсә Себергә сөрелгәч, аларның элемтәләре бөтенләй өзелә.

Гази үзенең Ватанына турылыклы хезмәт итү дәрте белән яна. Ул врач булырга хыяллана. Ләкин аңа үзенең хыялын тормышка ашыру насыйп булмый. 1942 нче елның кышында студент егет, үзе теләп, сугышка китә. Фашистларга әсирлеккә эләгеп, күп мәртәбәләр үлем белән күзгә-күз очраша. Фашизмның бөтен ерткычлыгын үз җилкәсендә татый, шундый шартларда могҗизалы батырлыклар эшли. Аны әсирлектән совет сугышчылары коткара, әмма егетнең әсирлектә булуы аның бөтен юлына киртәләр кора: Гази институтны тәмамалау мөмкинлегеннән мәхрүм ителә. Ул больницада хирург булып эшли башлагач, баш врач аңа мөһим операцияне ясатуны тыя: «Үткәне турында бик яман хәбәр алынды», – ди. Хаксызга рәнҗетелүләр ахыр чиктә Газины аяктан егалар. Ул Ватанның турылыклы улы икәнен, Туган ил алдында намусы саф, вөҗданы пакь булуын исбат итәргә тели. Әсәрдә без дөреслекнең тантана итүен күрәбез: Газиның әсирлектә күрсәткән батырлыкларының тере шаһиты – Кремнев табыла. Ул, Газига операция ясаганда, аның йөзендәге ярасыннан танып ала. Газиның – Ватанның турылыклы улы булуы бөтен дәлилләр белән исбат ителә. Аның герой икәнлеге, моңа кадәр исә бөтенләйгә гаепсезгә эзәрлекләнүе, ә чынлыкта зур геройлык эшләгән кеше икәнлеге бөтен больница персоналына барып ирешә.

Әсәрдә Гази белән Гөлүсәнең мәхәббәтен укучылар күңел тетрәндергеч итеп сурәтләнүен билгеләп үтәләр. Чыннан да, Гөлүсә Газиның күңелендә мәңгелек яра булып яши. Иң авыр чакларда ул аның белән күңеленнән серләшә. Гөлүсә дә гел Газины уйлый, аның белән күрешүгә омтыла. Бу мәхәббәт Гөлүсәне батырлыкларга канатландыра. Туган яктан еракта да Гөлүсә чын кеше булып кала. Югары белем ала, баш ветврач дәрәҗәсенә күтәрелә, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты була. Сугыш елларында ятим калган баланы үз кызы кебек тәрбияләп үстерә. Аны лачын кебек гүзәл егетләр ярата, ләкин Гөлүсәнең күңеле гел Газида, ул әнә шул яшьлек мәхәббәтенә турылыклы.

Укучылар романның соңгы битләре аеруча дулкынландыргыч булуын әйттеләр. Гази белән Гөлүсәнең гомерлек хыяллары тормышка аша: хәтсез еллардан соң алар очрашалар. Язучы бу

күренешне тетрәндергеч итеп, гаять зур психологик осталык белән сурәтләп бирә.

Әсәрнең ахырында Гази үлә, әмма дөреслек, хаклык өчен көрәштә җиңеп үлә.

Романда укучының күңеленә хуш килә торган образларның берсе – Себер егете Лачын. Бу батыр егетнең тайгада аю белән бергә-бер сугышу картинасын укыганда йөрәк кысыла, күз алдына әкият батыры килеп баса. Лачын Гөлүсәгә аю тиресе бүләк итә. Ул Гөлүсәне чын күңелдән ярата. Ватаныбыз өчен иң хәтәр көннәрдә, фашистлар Мәскәү астында чагында, сугышка китә. Панфилов дивизиясендә булып, политрук Клычковның: «Чигенергә бүтән урын калмады, артыбызда Мәскәү!» дигән чыгышын тыңлый. Лачын Мәскәүне дошманнан саклап калу өчен барган дәһшәтле сугышта һәлак була.

Иргали, Гази, Гөлүсә образларына хас сыйфатларны таптыру укучылардан гомумиләштерә белүне, нәтиҗә чыгаруны таләп итә. Иргали, Гази, Гөлүсә – романның төп геройлары, катлаулы язмышлы кешеләр. Алар дөреслек, хаклык өчен көрәшәләр һәм җиңүгә ирешәләр. Аларның һәркайсы үзенең төп максатын илгә игелекле хезмәт итүдә күрә. Язмышның текә борылышларында, иң авыр хәлләргә тап булганда да, чын кешеләр, ил батырлары булып калалар. Укучылар әнә шундый нәтиҗәгә киләләр. Шушы урында М. Җәлилнең «Кешелек турында» («Бер үгет») шигырен бер укучы сөйләде. Бу гаять тәэсирле булды.

Әсәрнең әһәмиятенә карата укучылар кызыклы фикерләр әйттеләр. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

«Язгы аҗаган» романы – үзгәртеп кору эшенә җитди өлеш кертә торган югары художестволы әсәр. Биредә язучы Мәхмүт Хәсәнов шәхес культы чорында халкыбыз кичергән ифрат зур гаделсезлекләрне, аларның сәбәпләрен, шуларны тудырган кешеләрне ачык һәм кыю сурәтләгән. Гаделлекнең, матурлыкның бәясе бервакытта да төшми. Романның төп геройларындагы күркәм сыйфатлар без күрергә теләгән яңа кеше сыйфатларына туры килә. Җәмгыятебездә башланган яңарыш чорына кадәрге елларда да үзенең кешелек, югары әхлак сыйфатларын горур рәвештә саклап калып, риясыз, ихлас күңелдән Ватанга хезмәт иткән кешеләр илебез тарихында лаеклы урын алыр.

М.Хәсәнов биредә ялган, ялагайлык, шымчылык, икейөзлелек, эчкечелек, рухи һәм матди спекуляция кебек тискәре күренешләрнең тырыш, гадел хезмәт кешесе өчен ят булуын ачык күрсәтә. Гаделләр өчен еллар, заман авыр булган. Безгә боларны белергә кирәк. Гаделсезлек, хаксызлык бервакытта да кабатланмасын өчен белергә кирәк.

Конференция-диспутны йомгаклау рәвешендә бер укучы шагыйрь Р. Фәйзуллинның «Көрәшчеләр кирәк!» поэмасыннан өзек сөйләде.

1988

**Дж. Лондонның “Яшәү теләге” хикәясе буенча китап укучылар конференциясе**

Бу әсәр буенча китап укучылар конференциясен без V – VII класс балалары белән үткәрүне хуп күрәбез. Ни өчен дигәндә, әлеге әсәр шушы класс балаларының яшь үзенчәлекләренә бик туры килә, аның идея-эчтәлеге батырлык, гаделлек кебек күркәм сыйфатлар тәрбияләү көченә ия.

Шушы хикәя буенча китап укучылар конференциясе үткәргәндә, алга тагын бер максат куябыз. Ул шуннан гыйбарәт. Татар теленә дөнья классикларының байтак әсәрләре тәрҗемә ителгән, балаларда шулар белән кызыксынуны арттырырга, чит ил әдипләренең прогрессив идеяле әсәрләре белән таныштырырга кирәк; шуның белән бергә укучыларны мөстәкыйль фикер йөртергә, дөрес нәтиҗәләр ясый белергә өйрәтү, шушы хикәя аша аларда рухи нык-лык сыйфатларын үстерү, аларга эстетик тәрбия бирү – болар барысы да гаять әһәмиятле.

Әлеге әсәр буенча конференция үткәреләчәге турында бер ай алдан кисәтеп куела. Хикәянең эчтәлеге буенча рәсемнәр ясарга тәкъдим ителә (әлбәттә, ирекле рәвештә). Укучыларга әсәрне укып чыгу өчен мөмкинлек булдырыла, сораулык эленеп куела. Мәсәлән:

1. Хикәядә вакыйга кайда бара?
2. Әсәр кемнәр турында язылган?
3. Биль иптәшен ник ташлап китә?
4. Язучы тундра пейзажын ничек тасвирлый?
5. Ялгыз калган кеше яшәү өчен ничек көрәшә?
6. Ялгыз кеше кем турында уйлый?
7. Кешенең аю белән көрәшен тасвирлап сөйләргә.
8. Кешенең бүре белән көрәшен тасвирлап сөйләргә.
9. Хикәядә диңгез пейзажы ничек бирелгән?
10. Әсәрнең эчтәлегенә карата нинди мәкальләр куллана алыр идегез?

Конференция үткәрелә торган зал Д. Лондонның портреты, китаплары, аның тормышы турында бюллетень, дөнья картасы, тундраны сурәтләгән картиналар белән җиһазлана.

Түбәндә кыскача гына конференциянең барышына тукталабыз.

Башта алдан әзерләнгән укучы Дж. Лондон турында белешмә бирә:

– Джек Лондон 1876 нчы елда АКШның Сан-Франциско шәһәрендә туган. Әтисе, Джек туганчы ук, семьясын ташлап китә. Шуннан соң әнисе бер ярлы фермерга кияүгә чыга. Үги әтинең эшләп тапканы ишле гаиләне туйдырырга җитми, алар искиткеч мохтаҗлыкта яшиләр. Шунлыктан Джекка тормыш ачысын бик

яшьләй татырга туры килә. Ун яшь тулганда инде ул урамда газеталар сатып акча эшли башлый. Ундүрт яшендә консерв фабрикасына эшкә урнаша. Аннары, балык тоту шхунасына матрос булып ялланып, Япония ярлары буена чыгып китә.

Ул бик озак дөнья гизә. Американы аркылыга-буйга йөреп чыга. Алтын эзләүче буларак, Аляскага да барып җитә. Кайларда гына михнәт чигеп йөрми ул!

Лондон кечкенә чактан ук язучы булырга хыяллана. Төннәрен баш күтәрми укый.

Искиткеч зур тырышлык кую нәтиҗәсендә максатына ирешә: бөтен дөньяга танылган мәшһүр язучы булып китә.

Джек Лондон 40 еллык гомерендә (ул 1916 елда үлгән) 150 дән артык хикәя, дистәләгән роман һәм повестьлар язып калдыра.

Укытучы. Менә, укучылар, сез Джек Лондонның кыскача гына биографиясе белән таныштыгыз. «Яшәү теләге» хикәясе белән язучының үз тормышы арасында охшашлык бармы?

Укучылар охшашлыкны тиз билгелиләр. Чөнки «Яшәү теләге» хикәясендә вакыйга Америка материгының иң төньягына урнашкан Аляскада бара. Джек Лондон үзе дә яшь чагында анда алтын эзләп йөргән икән. Шуннан соң чыгыш ясаучы укучы алтын эзләп кайтучы ике кешегә кыскача гына характеристика бирә. Аларның берсе – Биль иң авыр чакта иптәшен ташлап китә. Чөнки ул, аягын авырттырган кеше белән тиз генә кайтып җитеп булмас, аңарга булышып азапланасы бар, үземә генә яхшырак булыр, дип уйлый. Ләкин ул бик нык ялгыша. Үзе дә фаҗигале төстә һәлак була, иптәшен дә тундра кочагында япа-ялгыз калдыра. Бильне бүреләр ашап үтерә. Татар халык мәкалендәгечә килеп чыга: «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар».

Укытучы. Кеше Канаданың очсыз-кырыйсыз тундрасында япа-ялгыз кала. (Картадан күрсәтелә.) Хикәядәге кеше менә шушы Дәү Аю күленнән Макензи елгасы Төньяк Боз океанына койган урынга таба бара. Тундра пейзажы. Джек Лондон тундра пейзажын ничек сурәтли икән, шуны табып, сәнгатьле итеп укып күрсәтегез әле.

Бер укучы: «Ни агачлар, ни куаклыклар, ни бер үлән заты – иксез-чиксез шомлы чүлдән башка берни дә юк» дип башланган абзацны укый. Аннары укытучы игътибарны ялгыз калган кешенең яшәү өчен көрәшен язучының ничек сурәтләп бирүенә юнәлтә (бу эш балаларның художестволы хәтерен үстерүне күз алдында тота): “Ул үзенә ашарга таба алмый. Сазлык җиләкләрен өзеп ашый. Вак-вак күлдәвекләрдән бармак буе ташбашлар тотып, аларны чи килеш ашап туклана. Алтын янчыгын ташлап калдыра. Ләкин чиләген һәм пычагын ташламый. Шырпыларын корыда саклый. Ул сазлыклар, яңгырлы карлар, очлы ташлар аша алга атлый. Хәлдән тайгач, дүртаяклап, мүкәләп, өстерәлеп, шуышып, үрмәләп бара. Нык ихтыярлы кеше була ул. Бөтен тәне җәрәхәтләнеп бетә, ачлыктан

саташа, җеп өзәрлек хәле калмаса да, алга таба баруны дәвам иттерә...”

Укучылар үз фикерләрен әйтәләр: кешенең башкалар турында да кайгыртуына игътибар итәләр. Өендә аның ялгыз әнисе калган. Ул үзенең әле әнисе хакына да яшәргә тиешлеген аңлаган.

Укытучы. Коточкыч урыннардан уза кеше. Әйләнә-тирә тулы бүре, аю... Әйдәгез әле, кешенең аю белән көрәшен тасвирлап сөйләп бирик.

Балалар шул хәлнең әсәрдә ничек тасвирлануы турында сөйлиләр. (Шул уңайдан китаптан аеруча тәэсирле юллар укып та күрсәтелә. Мәсәлән: «Ничек тә дәһшәтлерәк күренергә тырышып, торып басты да, пычагын тотып, туп-туры аюның күзенә карады».) Аннары бүре белән көрәш вакыйгасы күздән кичерелә: «Менә бүренең казык тешләре аның кулын башта салмак кына, ә аннары һаман саен ныграк кысарга тотындылар». Кеше бүрене җиңә. Бильнең һәлакәте болай сурәтләнгән: “Юеш мүк өстендә кимерелгән сөякләр – Биль сөякләре. Ул алтынын ташламаган. Алтын янчыгын бүренең очлы тешләре тишкәләп бетергән...”

Кеше, мең газапларны җиңеп, диңгез буена килеп җитә. Диңгез пейзажы бәхет, теләккә ирешү символы кебек кабул ителә. «Җемелдәп торган якты диңгез» образы бездә шатлык хисләре уята.

Укучылар эчтәлеккә туры килә торган байтак мәкальләр эзләп тапканнар: «Тырышкан таба», «Бәхет батырларга ачыла», «Тәвәккәл таш ярыр», «Юлга чыксаң, иптәшең үзеңнән яхшы булсын» һ. б. 1990

## Сәләтле балалар белән эшләү тәҗрибәсеннән

Соңгы елларда һәр мәктәптә, сәләтле балалар белән эшләү программасы төзелеп, шул юнәлештә бик күп төрле чаралар үткәрелә. Дөресен әйткәндә, бу – яңалык түгел, аерым укытучылар элгәре дә бу юнәлештә бик нәтиҗәле эшлиләр иде.

Мин үзем дә, татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, сәләтле укучыларны үстерү өлкәсендә күп еллар буе эшләп киләм. Безнең мәктәптә, гомумән, татар теле һәм әдәбиятын укыту эше элек-электән яхшы куелган иде, сәләтле балалар белән эшләү беренче планда тора иде. 33 укучыбызның татар филологиясе фокультетына кереп уңышлы укулары һәм яхшы белгечләр булып эшләүләре шуның ачык нәтиҗәсе булып тора. Район буенча үткәрелгән олимпиадаларда, конкурсларда да безнең укучылар алдынгы урыннарны яулап киләләр. Фәридә Әнвәр кызы Нуруллина – талантлы педагог һәм шагыйрә дә.

“Кешегә бетмәс-төкәнмәс иҗат чыганагы салынган, менә шул чыганакны ачарга, иреккә чыгарырга, кешегә иҗтимагый тормышта урынын табарга булышырга, аңа, үсү өчен, тиешле шартлар тудырырга кирәк, – дип язган Лев Толстой. Укытучының үзенең

иҗади сәләткә ия булуы – балаларның иҗади сәләтен үстерүнең мөһим шарты.

Кайбер кешенең хәтергә алу сәләте бик нык үскән була. Әмма бу башка төр сәләтләр исәбенә үсә. Хәтердә калдыру сәләте көчле үскән кешеләр иҗади сәләткә ия булмыйлар. Хәтердә калдыру сәләте бик нык үскән галимнәрне тарих белми әле. Әгәр дә бала телевизор экранында күргәннәрен бик озак вакытка хәтерендә калдырса, тиздән ул начаррак укый башлаячак. Иң мөһиме: баланы уйларга өйрәтергә кирәк. Тел-әдәбият дәресләрендә табышмакларга җавап таптыру шул юнәлештә  отышлы эш булып тора. Бала җавабын берничә көн буе эзләп таба торган табышмакларны сайлап алырга кирәк.

Сәләтле бала нинди була соң ул?

Гадәттә, мәктәп программасын үзенең яшьтәшләренә караганда тизрәк һәм тирәнтенрәк үзләштерә торган укучыны сәләтле дип атыйлар. Ул  фактларны, исем, фамилияләрне, кагыйдәләрне җинелрәк исендә калдыра, яңа теманы тизрәк үзләштерә, мәсьәләләрне тизрәк чишә, хатасыз яза. Хәзерге заман фәне баланың кече яшьтән үк нәрсәгә сәләтле, һәвәс булуын билгели ала.

Дәрестә сәләтле балалар белән эшләү барлык балаларга да төпле һәм ныклы белем бирүне тормышка ашыруга һич тә камачаулык итәргә тиеш түгел. Дәрестә сәләтле балалар белән эшләүне уртача эзерлектәге балаларга да файдалы итеп оештырып була. Татар телен укыту барышында мин, сәләтле балаларны даими үстерү өчен, махсус картачкалардан киң файдаландым. Талантлы укучыларга, грамматик анализ ясау өчен, иң катлаулы мисалларны бирәм.

Тыныш билгеләре куюның кыен очракларын  алар белән махсус өйрәнүне оештырам. Контроль эшләр вакытында сәләтлеләргә аерым биремнәр тәкъдим итәм. Укучыларның сәләтләрен үстерүдә бербөтен текст өстендә эшләү әйбәт нәтиҗәләр бирә, чөнки текст эчендәге барлык бәйләнешләрне таба белү бик зур логик фикерләү осталыгын таләп итә. Тексттан стилистик чараларны, сурәтләү чараларын, поэтик синтаксис  берәмлекләрен таптыру белән беррәттән, лексик, грамматик, фонетик яктан тикшерүне дә үткәрәм. Нәкъ менә текст өстендә эшләгән вакытта укучыларның һәм татар теленнән һәм әдәбияттан алган белемнәре берьюлы иҗади эшкә җигеләләр.

Сәләтле укучыларның бәйләнешле сөйләм осталыкларын үстерүдә сочинениләр яздыруга аеруча игътибар бирәм. Бу өлкәдәге тәҗрибәләремне мин “Мәгариф” журналында басылган мәкаләләремдә язып чыккан идем ( “V сыйныфта сочинение яздыру”, “М.Хәсәновның “Язгы аҗаган” романы буенча дәрес-конференция”, “Сыйныфтан тыш уку дәресен оештыру”, “Вәисовлар хәрәкәтен өйрәнү”).

V сыйныфтан башлап ук сәләтле укучыларны сочинениегә материал туплау серләренә өйрәтәм. Әлбәттә, кирәкле материалны үземнең шәхси китапханәмнән дә бирәм. Сочинениеләрне анализлау

эшен зур әзерлек белән башкарам. Иң беренче чиратта, сочинениедәге унышлы якларны күрсәтәм, укучыны иҗади осталыгы белән дәртләндерәм, кечкенә генә әдәби табышларын да күрергә һәм шуларны үстерергә тырышам. Хаталар өстендә эшне классификация ясау методы белән алып барам.

Сыйныфтан тыш уку буенча күрсәтмә һәм өстәмә материалларны алдан ук – җәйге каникуллар алдыннан ук бирәм. Сәләтле балаларга, әлбәттә, үзем махсус төзегән әдәбият исемлеген тәкъдим итәм. Матур әдәбият буенча гына түгел, әдәбият белеме буенча да байтак гына китапларны укырга кушам. Сыйныфтан тыш уку дәфтәрләрендәге язмаларның иҗади характерда булуларын таләп итәм. Мәсәлән, XI сыйныф укучысы Нуруллина Энҗе үзе укып чыккан әсәрләргә – Нурихан Фәттахның “Кичү” романына, Аяз Гыйлаҗевнең “Ягез, бер дога” романына, Фатих Хөснинең “Авыл өстендә йолдызлар” повестена карата тулысынча мөстәкыйль характерда булган рецензияләр язган иде. Ә Газимҗанова Рузилә хатын-кыз шагыйрәләр Клара Булатова, Саҗидә Сөләйманова, Лена Шагыйрьҗан әсәрләренең поэтик үзенчәлекләре турында үз карашларын бик үтемле итеп язып күрсәткән иде. Сыйныфтан тыш уку дәфтәре – ирекле, демократик дәфтәр ул. Анда укучы үз күңелен, үз уйлаганнарын ирекле формада яза ала. Әсәр укыганда үзен әсир иткән, сискәндереп җибәргән урыннарны шул дәфтәргә күчереп тә куя ала. Көндәлек газеталардан өземтәләрне дә шунда урнаштыра ала. Күп еллардан бирле мин шул дәфтәрләргә иллюстрацияләр дә, орнаментлар да ясатам. Татар теле һәм әдәбияты түгәрәгенә сәләтле балалар бик теләп йөриләр. Монда без барлык әдәби жанрларның үзенчәлекләрен өйрәнәбез, хәбәрче булу серләренә төшенәбез. Күп еллардан бирле “Әдәби сүз” дигән стена газетасы һәм “Әдәби альманах” дигән кульязма журнал чыгарып киләбез. Яшь талантлар үз әсәрләрен әдәби кичәләрдә укыйлар, үзләре язган пьесалар буенча спектакльләр куялар. Безнең түгәрәк әгъзаларының әсәрләре “Яшел Үзән”, “Сабантуй”, “Көмеш кынгырау” газеталарында басыла тора, шулай ук алар Яшел Үзән һәм Казан телевиденисе тапшыруларында да күренгәли киләләр. Рамилә Майорованың әсәрләре Казанда “Өмет бар туар көннәремдә” дигән аерым бер китап булып басылып чыкты.

Сәләтле укучыларыбыз, татар филологиясе факультетында укыганда, бик теләп һәм уңышлы рәвештә иҗат эше белән шөгыльләнәләр. Диплом темаларын үзебез җирлектән, үзебез тарихтан сайлап алалар. Мәсәлән, Фирдәүсә Сафинаның “Мулла Иленең топонимиясе”, Равилә Сәйфетдинованың “Гомәр Саттарованың гыйльми эшчәнлеге” дигән диплом эшләрен күрсәтергә була. III сыйныфта укыганда ук вакытлы матбугатка язышa башлаган Рузилә Газимҗанова үзебезнең “Яшел Үзән” газетасында журналист булып эшли. Талантлы укучыбыз Илсөяр Шәкурова бүген гыйльми эш алып бара, тирән эчтәлекле хезмәтләре

дөнья күрә килә. Ә Фәния Гыйzzәтуллина фәннәр академиясендә уңышлы рәвештә текстолог булып эшли.

Без сәләтле укучылар белән төрле чаралар оештырабыз. Югары сыйныфтагы укучыларның түбәнге сыйныфларда укытучы роленә кереп дәрес үткәрүләрен дә оештырган идек. Нәкъ менә шунда, үзен укытучы итеп сизгәндә, сәләтле укучының бөтен хәзинәсе балкып-ачылып китә икәнлеген күрдек.

Сәләтле укучылар язган рефератлардан күргәзмәләр оештырабыз, конкурслар үткәрәбез.

Сәләтле укучыларга мәйдан кирәк, үзләренең иҗади көчләрен күрсәтү өчен төрле-төрле форумнар кирәк. Шуңа күрә дә безнең мәктәптә әдәби кичәләр, диспутлар, конференцияләр, викториналар, әдәби лекцияләр һәм докладлар еш була. Сәләтле укучылар “Авылдашларыбыз Баһаветдин һәм Гайнан Вәисовлар”, “Гайнан Вәисов һәм Лев Толстой” дигән темаларга тирән эчтәлекле әдәби кичәләр, конференцияләр үткәрделәр, Татарстанның атаклы рәссамы Мансур Рәхимовның “Лев Толстой һәм Гайнан Вәисов” дигән картинасы буенча рефератлар яздылар. Сәләтле укучылар белән җирле материалларны ничек өйрәтү һәм туплавыбыз турында мин “Мәгариф” журналында “ Мулла Иле – изге урын” дигән мәкаләмдә язган идем.

Әдәбият, тел дәресләре нәфис сүз, театр, кино, рәсем, җыр, балет сәнгатьләре белән аерылгысыз бәйләнгән. Шуңа күрә дә безнең мәктәптә аларны комплекслы үстерү эше алып барыла.

Сәләтле укучыларны нәфис сүз сәнгатенә кечкенәдән башлап ук өйрәтә киләбез. Театр өлкәсендә уңышларыбыз аеруча сизелерлек. Безнең мәктәп сәхнәсендә чыныккан Нияз Шакиров Казанда уңышлы рәвештә театр училищесында укый.

Безнең мәктәптә өстәмә белем бирү системасы инде камилләшеп җиткән. Өстәмә белем бирү педагогы Зөләйха Сафина җыр, хор, баян, театр, нәфис сүз, музыка сәнгатьләрен үстерү буенча күп эш алып бара. Тел-әдәбият укытучылары белән кулга-кул тотынып эшли. Авыл мәдәният йорты директоры, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Гөлинә Габделхәева сәләтле балалар белән эшләүгә күп көч куя.

Шулай итеп, сәләтле балалар белән эшләү – заман таләбе ул, бу өлкәдәге эшләрне алга таба тагын да кызыклырак, эчтәлеклерәк итеп алып барырга кирәк.

26.02.2002

**Толстойча фикер йөртү**

Үзең сөймәгән, үзеңне рәнҗеткән кешене яратырга тырыш. Әгәр дә моны булдыра алсаң, шундук күңелең күтәрелеп, яктырып китәр. Үз-үзеңне төзәтә барып, һәр көн, һәр сәгать саен аз гына булса да яхшыра барырга тырышырга кирәк. Гомернең иң мөһим һәм иң күңелле гамәле менә шунда.

Үз акылың белән яшәргә кирәк. Сине рәнҗеткән, сиңа явызлык кылган кешенең усал тойгылырына бирелмәскә кирәк. Киресенчә, явызлыкка миһербанлык белән җавап бирергә кирәк. Әгәр явыз кешеләр белән явыз булсаң, тиздән мәрхәмәтле кешеләр белән дә явыз булачаксың.

Әгәр берәү, икенче кешегә һөҗүм итеп, аны рәнҗетсә, ул шуның белән аңарда бөтен усаллыкның тамыры булган нәфрәтне кабыза. Шушы явызлык хисен сүндерү өчен нишләргә соң? Бу явызлык хисен китереп чыгарган нәрсәне эшләргәме? Шулай эшләү, димәк, явызлыкны юкка чыгару урынына, аны көчәйтү генә була.

Шуның өчен дә явызлыкка явызлык белән каршы килмәү явызлыкны җиңүнең бердәнбер чарасы. Фәкать ул гына явыз хисне үтерә – аны эшләгән кешедә дә һәм аннан зарар күрүчедә дә.

Бүген эшли алырлык изге гамәлләреңне иртәгә калдырма. Кеше кылырга теләгән изгелеген эшләп бетергәнме-юкмы, үлем аны тикшереп тормый. Үлем беркемнең дә эшләп бетергәнен көтеп тормый. Кешенең эшләргә өлгергән гамәлләре аның язмышы була. Язмыш яхшы да, начар да була ала. Шуңа күрә дә кеше өчен дөньяда иң мөһиме – аның бүген кылган гамәле.

Барлык диннәрдә дә ничек яшәргә кирәклеге турындагы тәгълимат бер төрле. Йолалар төрле, ә иман бер төрле.

1995

## Матур сөйли белү – һәр кешенең изге бурычы

*Әйләнә-тирәдәгеләрегезгә игътибар иткәнегез бармы – буыннардан-буыннарга, әби-бабайлардан калган тел байлыгын кулланып, әңгәмәдәшләрне дә көнләштереп һәм кызыктырып, чит тел сүзләрен кулланмыйча матур сөйли белүчеләр күпме? Бармак белән генә санарлык. Матур сөйләргә теләсәк тә, күпләребез моны булдыра алмый. Булдыксызлыгыбызны яшерергә тырышабыз, табигать матур сөйләү осталыгыннан мәхрүм иткән мине, дип акланабыз. Шулай да матур сөйләргә кайда, ничек өйрәнергә? Моның берәр сере бармы? Әңгәмәдәшебез – үзешчән нәфис сүз осталарының Бөтенсоюз лауреаты, Мулла Иле урта мәктәбе мөгаллиме, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы Равил Гарәф улы Сәйфетдинов белән шулар хакында сөйләшәбез.*

– Без бала чакта нәфис сүз бик дәрәҗәле, абруйлы иде ул. Авыл клубы сәхнәсендә дә атаклы сүз осталары еш чыгыш ясыйлар иде. Әзһәр Яһудин, Фәйзи Йосыповларның сөйләүләрен бөтен дөньямны онытып тыңлый идем. Аннары аулак урында үзем дә нәкъ шуларга охшатып сөйләп карый идем. Ф.Кәримнең "Кыңгыраулы яшел гармун"ы, М.Садриның "Бәхет турында җыр"ы, Ә.Фәйзинең "Әүхәдинең Мәйшәкәр белән саубуллашуы", Һ.Такташның "Киләчәккә хатлар"ы, Г. Тукайның "Ысулы кадимче", М.Әмирнең юмористик хикәяләре кебек әсәрләрне алар кебек башкарырга тырыша

идем. Шулай итеп, мин бала чакта ук сәнгатьле сөйләмгә гашыйк идем. Ә гашыйк булгач, кеше барыбер өйрәнә инде ул. Хәтта дикциясе тумыштан бик үк әйбәт булмаган бала да. Әнә бит бөек грек ораторы Демосфен, авызына вак-вак ташчыклар каба-каба, авазларны дөрес, матур әйтергә өйрәнгән, аннары, диңгез ярына басып, су шаулавын басарлык көчле, аһәңле тавышка ия булырга өйрәнгән. Иң мөһиме – теләк, эчке омтылыш.

*– Равил абый, ләкин кешедә көчле теләк булсын өчен, нәфис сүзне җәмгыятьтә, тормышта кирәкле, зарури бер эш дәрәҗәсенә күтәрергә кирәк.*

– Килешәм. Без егет чакта мәшһүр сүз остасы Хәким Сәлимҗановның (мәрхүм Марсель Сәлимҗановның әтисе) "Нәфис сүз" дигән китабы басылып чыкты (1958 елда). Теория белән практика бергә үрелеп барган бу китаптан без нәфис сүз серләрен өйрәндек. Әле хәзер дә ул минем өстәл китабым булып тора. Хәзер дә мин балаларны сәнгатьле сөйләмгә шул китап методикасы буенча өйрәтәм. "Сәнгатьле сөйләмгә өйрәник" (1970) дигән китап та бик файдалы кулланма булып тора. "Мәгариф" журналлары тупланмасында нәфис сүзгә өйрәтү буенча күп кенә материаллар бар.

Мәгълүм булганча, чит илләр мәктәпләрендә беренче сыйныфтан башлап ук "Риторика" дигән предмет дәрес буларак укытыла. (Риторика – матур сөйләргә өйрәтүче фән). Ләкин бездә сәнгатьле сөйләм һаман да дәрестән тыш эш кенә булып кала бирә. Дәресләрдә ул предмет буларак укытылмый. Дөрес, без сәнгатьле уку турында күп сөйлибез, укучыларга сәнгатьле итеп сөйләргә кушабыз, ләкин алар үз ихтыярларында кала бирәләр. Шуңа күрә мәктәптә сәнгатьле сөйләм предмет буларак укытылырга тиеш. Бу – тормышта һәр кешегә кирәкле нәрсә. Нәфис сүз ул – югары әхлаклылыкка ирешүнең аерылгысыз бер өлеше. Әле күптән түгел генә безнең район мәктәпләрендә Мәгариф министрлыгы тикшерүләре булып узды. Тикшерү йомгакларында мин үземнең әлеге фикерләремне, тәкъдимнәремне сөйләп тә чыктым. Шунысы куанычлы: министрлык вәкилләре бик якын араларда мәктәптә нәфис сүзнең предмет буларак укытылачагына ышандыралар.

Без университетта укыган елларда нәфис сүзгә игътибар бик көчле иде. Нәфис сүз, драма түгәрәкләрендә безне күренекле артистлар Рәшидә Җиһаншина, Нәҗип Гайнуллин өйрәтте. Без Н.Исәнбәтнең "Муса Җәлил" трагедиясе шикелле катлаулы әсәрләрне Г.Камал театрында да, Арчага барып та куйдык һәм ул елларда әле яңа гына сафка баскан Казан телевидениесе аша да күрсәтә идек. Комсомол өлкә комитеты безне путёвкалар белән төрле урыннарга лекторлар итеп җибәрде. Мин үзем элгәреге Норлат районының барлык авылларында да лекцияләр укып йөрдем. Авыл җитәкчеләре аларда мәҗбүри катнашалар иде. Клублар һәрвакыт шыгрым тулы була иде. Лекцияләрне бик күп чыганаклардан файдаланып төзи идек, сүз белгечләре шул лекцияләрне ораторларча сөйләргә өйрәтәләр иде.

*– Равил абый, нәфис сүз – иҗатның бер төре, шуңа күрә аңа кеше гомере буе үзлегеннән күп өйрәнергә тиеш дип уйлыйм мин. Китаптан, профессиональ артистлардан, сүз дә юк, өйрәнү бик кирәк, әмма телне пычратмау өчен көндәлек үз өстеңдә эшләү дә зарури.*

– Мәктәптә эшләгән елларда гомер буе халыкка лекцияләр һәм докладлар укыдым. "Слово лектора", "Пропагандист", "Агитатор блокноты", "Политическое самообразование" һ.б. басмаларны һәрдаим укып бардым. Гомер буе пропагандист булып эшләдем һәм агитаторлар коллективын җитәкләдем. Ай саен семинарлар уздырдым. "Белем" җәмгыяте мине күп тапкырлар дипломнар белән бүләкләде.

Үзешчәннәрнең сәнгать смотрларында нәфис сүз жанры буенча гел катнашып килдем. Күп тапкырлар лауреат исеме алдым, дипломнар белән бүләкләндем.

Сүз дә юк, балаларны мәктәптән нәфис сүзгә өйрәтеп чыгарырга кирәк. Кызганыч, бүген яшьләр вульгар телдә сөйләшәләр, телдәге оятсызлык күңел бозыклыгын күрсәтеп тора ул. Кеше алдындагы чыгышлар да, интервьюлардагы җаваплар да, радио-телетапшырулардагы сөйләмнәр дә еш кына примитив, тупас, ярлы, кыланчык булалар. Хәтта сүз осталары үзләре, оригиналь булам дигән булып, кыланып җибәрәләр. Хәтта дәрәҗәле түрәләр сөйләме дә еш кына шыксыз, төссез. Һәр җөмлә саен тотлыгып, ык-мык килеп, "менә бу", "инде", "әйеме", "димәк", "теге бар бит әле" кебек сүзләрне атлаган саен кыстырып сөйләү – ямьсез, бик иләмсез күренеш. Ә бит халкыбыз сөйләме нинди матур! Ә бит язучыларыбыз әсәрләренең теле нинди гүзәл! Нигә шул байлык файдаланылмый? Тел сагында торучы цензура кирәктер ул. Эфирга ничек тә булса камил сөйләмне генә чыгарырга кирәк. Балалар шуннан өйрәнәләр бит. Һәр ике телдә дә – татарча да, урысча да матур сөйли белү – Татарстан гражданнарының, бигрәк тә җитәкчеләрнең, түрәләрнең, чиновникларның изге бурычы.

Сәхнәдән һич тә җыен тузга язмаганны сөйләтергә ярамый. Классик дәрәҗәдәге әсәрләр генә башкарылырга тиеш. Югыйсә, безнең үрнәк әсәрләр читтә калып торалар, ә арзанлы көлкегә корылган нәмәрсәләр сәхнәне тутыралар. Уңай герой образы бүген дә кирәк. Үрнәк һәрвакыт, һәр эштә кирәк.

*– Кызыклы әңгәмәгез өчен рәхмәт Сезгә, Равил абый. Укучыларыбыз Сезнең киңәшләрдән файдаланырлар дип ышанасы килә.*

Интервью алучы – Әлифел Таразова 2002

**Укыту – минем өчен иң зур бәхет**

*Равил абыйны мин мәктәп өчен туган киң күңелле, олы җанлы кеше дияр идем. Аның йөрәге синең нәрсә уйлаганыңны да сизә. Борчулы, авыр сораулар белән керсәң – ярдәм итә, кулыннан килгәннең барын да эшли.*

Рәмилә Майорова

*– Равил әфәнде, менә Сез дә 60 яшегезне тутырып киләсез. 38 ел буе гел шушы мәктәптә татар теле укытасыз. 30 елга якын берөзлексез директорлык вазифасын башкарасыз. Әйтегез әле, Сез үзегез бу язмыштан канәгатьме?*

– Артка борылып карасам, мин шундый нәтиҗәгә киләм: гомерне яңадан башлап җибәрергә насыйп булса, мин нәкъ шул юлдан үтәр идем. Мин мәктәпне чынлап та бик яраттым. Мәктәптә эшләүнең һәр көне минем өчен авыр да, шул ук вакытта шатлыклы да. Бу язмышны үзем сайлап алдым. Үткән гомеремнән бик канәгатьмен. Авылда ике туган йортым бар: берсе – туган нигезем, икенчесе – туган мәктәбем.

*– Укытучы буларак, Сез нинди уңышларга ирешә алдыгыз?*

– Гомер буе татар теле укыттым. Һәр дәрескә илһамланып, иман яңартып керәм. Укыту – минем өчен иң зур бәхет, шатлык. Дәрескә кергәч, яшәреп, җиңeләеп китәм, күңел күтәренкелеге биләп ала. Әлбәттә, сөенечләр көенечләр белән гел бергә яши. Балалар белән эшләү – гаять четерекле, гаять катлаулы хезмәт бит. Менә шул авырлыктан мин үземә бетмәс-төкәнмәс яшәү көче алам.

*– Беренче эш көнен хәтерлисезме? Дөрес, дистәләгән еллар узган, күпме сулар аккан.*

– Бик әйбәт хәтерлим. Шулай туры килде: мин өч фәнне бергә укыттым – рус, татар, немец телләрен. Алтмышынчы елларда укытучылар юк иде бит. Беренче дәресем рус әдәбияты булды. VIII сыйныфта Радищев биографиясен сөйләргә кирәк иде. Мин дәрестә күбрәк үзеңә сөйләргә кирәк дип күз алдына китерә идем бит. Радищевның биографиясен яттан сөйләдем, бик күп өзекләр укыдым. Сыйныфта 35 бала бар иде, тик мин бер баланы да күрмәдем. Дәреснең башыннан ахырына кадәр сөйли-сөйли кыңгырау чылтыраганын белми дә калдым. Укучылар нәрсә кичергәндер – әйтүе кыен. Укытучы өчен иң мөһиме – үзең сөйләгәндә баланы күреп тору, сине тыңлыйлармы-юкмы – шуңарга игътибар итү. Беренче дәресне һаман да елмаеп искә алам. Ул дәрес белән хәзерге дәрес арасында – җир белән күк аермасы. Әмма аның охшашлыгы да бар. Әдәбият дәресендә балаларга эзлекле рәвештә, аларның күз алдына китерерлек картиналар тудырып тәфсилләп сөйли белергә кирәк. Бу – эшемдә төп үзенчәлек булып тора. Еллар үткән саен, бала белән индивидуаль эш итәргә, күбрәк баланы эшләтергә, һ.б. алымнарга өйрәнә бардым

*– 40 елга якын укыту дәверендә күңел түренә кереп калган укучыларыгыз күп булгандыр.*

– Үз гомеремдә укучыларым күп булды инде. Хәтта аның иң тәртипсез саналганы да минем өчен бик кадерле. Иң истә калган

укучым – әлбәттә, Руслан Гайнетдинов. Ул да мине бервакытта да онытмас. Шулай көннәрдән бер көнне мәктәпкә бер баланы китерделәр. Ул Волжск шәһәрендә IV сыйныфны бетергән. V сыйныфтан башлап күп мәшәкатьләр тудырды. Ул безнең мәктәптә моңа кадәр күрелмәгәнчә тәртип бозды. Моны ничек тәрбияләргә икән дип баш ваттым. Эш бүлмәмә чакырдым да, аңа Афзал Шамовның "Озын мыеклы абый" китабын укырга тәкъдим иттем. Анда бер хулиган малай турында сүз бара бит. Ул укып чыккан. Кечкенә китап, ләкин урыс мәктәбендә укыганга күрә аңа укуы авыр. Татарча начар белә иде. Китапның эчтәлеген сөйләп чыкты. Тәртибе үзгәрер дип уйлаган идем, әмма юкка. Шулай берничә ел узды. Мин аны бер дә игътибар үзәгеннән читкә җибәрмәдем. IX сыйныфта үзгәрде. 107 нче урта ПТУга укырга керде. Анда бик әйбәт сыйныф җитәкчесе туры килде. Хәзер III курста. Әйбәт укый. Тракторчы һөнәрен үзләштерә. Практикага кайтканда, бер эштән дә баш тартмый. Мине күрсә, бер чакрымнан сәлам бирә. Мәктәпне тәмамлаганда, аңа Ибраһим Газиның "Балачак" дигән китабын бүләк иттем. Күңелгә бик якын Руслан. Тырыш хезмәтнең куанычлы яклары да бар инде. Руслан әйбәт, ышанычлы кеше булыр дип уйлыйм. Аның уңышларына бөтен коллективыбыз сөенә. Әбисенә дә булыша. Бүген шук, усал малайлар юк. Аерылып тора торган малайлар бар. Күп сөйләп, күп сораулар биреп укытучыларны “аптырата” торган укучылар бар. Уку отличнигы Гөлнара Нуруллина мәктәпнең бөтен җәмәгать эшендә актив катнаша.. Күп фәннәр буенча олимпиадаларда әйбәт нәтиҗәләр күрсәтә. Көрәш секциясе уңышлы эшли. Рөстәм Хөсәенов район, республика күләмендәге ярышларда менә дигән итеп көрәште. Ләйлә Сәләхиева кызлар арасында үткәрелгән "Гыйффәт туташ" бәйгесендә җиңеп чыкты. Мәктәпне уңышлы тәмамлады, укуын медицина университетында дәвам итә. Бер укучыбыз үз көче белән университетның юридик факультетына керде. Икенче укучыбыз рәхәтләнеп кирпеч заводында эшли, ул әле укуын дәвам итәр дип ышанам. Сәләтле балаларны үстерү буенча юнәлешле эш алып барабыз.

– *Директор буларак, үзегез ирешкәннәрдән иң мөһиме итеп нәрсәне саныйсыз?*

– Мулла Иле урта мәктәбенең традицияләрен саклауны, авыл тарихына олы мәхәббәт тәрбияләүне. Безнең авылда XIV - XV гасырларда ук милли мәдрәсәләр булып, аларда галим-мөгаллимнәр дәрес биргәннәр. XIX гасырда Мулла Иле мәдрәсәсендә атаклы Вәисовлар укыган. Бу гасыр башында авылда татар-рус мәктәбе ачылган. Мәктәбебез күптәннән бирле икетеллелекне үстерү проблемасын уңышлы хәл итеп килә. Шуңа күрә дә без Казан югары уку йортларының татар һәм рус филологиясе кафедралары өчен терәк мәктәп булып торабыз. Бездә әлеге проблемалар буенча семинарлар

үткәрелә, студентлар педагогик практика үтәләр. Мәктәптә туган якны өйрәнү музее уңышлы эшләп килә.

*– Равил әфәнде, җитәкче кеше каты куллы булырга тиеш дигән фикер яши. Сез моның белән килешәсезме?*

– Мин – тормышта йомшак кеше. Әнидән йомшак күңелле булып туган. Бу өстәмә проблемалар, кайбер мәсьәләләрне хәл итүдә кыенлыклар тудыра, ләкин вакытлы кыенлыклар. Тора-бара кешеләр сине аңлыйлар инде, чөнки коллектив белән гел тату, дус яшәдем. Безнең бөтен мәктәп минем йомшак күңелле кеше булу системасына көйләнгән. Кычкырып йөрүләр юк. Педсоветлар тыныч уза. Йомшак күңелле кеше – гаделлек ярата торган кеше ул. Ә мин бөтен нәрсәдә, бөтен эштә гадел булырга тырышам. Гаделлекне яклауда принципиаль булырга туры килә. Законны бозмыйча эшләргә тырыштым. Рәнҗетелгәннәрне якларга, хезмәт куйган укытучыларны күтәрергә омтылдым. Безнең мәктәптә барлыгы 23 укытучы эшли. 2 укытучы – югары, 8 укытучы – I, 10 укытучы – II категорияле. 3 яшь белгечебез бар. Былтыр XI сыйныфны 10 укучы тәмамлады, 4 укучы югары уку йорты студенты булу бәхетенә иреште.

Дөньяда идеаль кеше юк, дип әйтергә яратсак та, укытучы үрнәк булырга тиеш. Бала мәктәптән кайткач, укытучысы кебек киенергә, сөйләшергә, елмаерга тырыша икән, димәк, ул аннан үрнәк ала, аныңча яшәргә омтыла дигән сүз.

*– Иҗатыгызга күз салсак, әниегезгә атап язылган шигырьләр байтак.*

– Әтием сугышта һәлак булган. Шуңа күрә әни минем өчен әти дә булды. Сердәшем дә, авыр чакта таянычым да ул иде. Хәзер вафат, шулай да миңа юл күрсәтүче булып яши минем күңелдә. Еллар үтү белән, әнигә караш үзгәрә. Бала чакта бер төрле яратсак, еллар узгач, әнинең хәсрәтләренә тирән мәгънә бирәсең. Тагын да күбрәк ярата башлыйсың.

*– Әниегезне хөрмәтләү, аны ярату хисе шигырь язарга этәргеч биргәндер.*

– Мин ялгызым гына үстем. Әби, әни тәрбиясендә. Әби туксанга кадәр яшәде. Халык авыз иҗатын бик яхшы белә иде. Бәетләр әйтә иде. Җырларга яратты. Олы кайгы кичерде: өч улы сугыш кырында ятып калды. Әни дә китапны ярата иде. Чоры да шундый туры килде: радио, телевидение юк. Без әдәбият белән яши идек. Бөтенесе бергә этәргеч биргәндер инде.

*– "Яшел Үзән" дусларын барлый" дигән әдәби-музыкаль кичәдә Сезнең шигырь укуны тамашачы Айрат Арслановка тиңләде. Шундый ук көчле тавыш, пафос, аһәң.*

– Башлангыч сыйныф укытучысы Фаика апа Балтанова гаҗәп күп укый иде. Үзе укыганнарның бөтенесен безгә сөйләп барды. 4 сәгать укыганнан соң тагын 2-3 сәгать аның сөйләгәнен тыңлап утыра, мәктәптән караңгы төшкәч кенә кайта идек. Оста оратор

булды. Шигырьнең эченә кереп, кешегә җиткерерлек итеп укый иде. Ул сөйләгәннәрне образга кереп, балаларча уйнап та күрсәтә идек. Рус теле укытучысы әдәбият белән "җенләнгән" кеше иде. Берсе дә эзсез узмагандыр.

*– Бүген нинди шигырь иҗат итәсез?*

Шигырьне мин гомер буе язам. Бүген авылдашларыбыз Баһаветдин һәм Гайнан Вәисовлар турында әсәр язып ятам.

*– Мөгаллим, шагыйрь Равил Сәйфетдиновның язу өстәлендә бүген нинди китап ята?*

– Китаплар күп. Олыгая башлагач, күбрәк философиягә өстенлек бирәм. Толстойның дөньяга карашлары турында калын китап җанымны биләп алды. Ул миңа бик кызыклы. Һәм аннары, өлкәнәя барган кешеләрнең һәрберсе шулайдыр инде, үзебезнең дини әдәбиятны бик күп укыйм, чөнки бөтенесен белергә телим. Татар әдәбиятын, яңа чыккан әсәрләрне укып барам. Картрак шагыйрьләр, язучылар китапларын кулга еш алам. Тирәнрәк, мәгънәлерәк әйберләр укыйсы килә. Яшьләр иҗаты белән дә кызыксынам. Бик матур яза торган шагыйрьләребез бар. Әдәбият саекмасын иде.

*– Кызыклы әңгәмәгез өчен Сезгә зур рәхмәт. Юбилеегыз белән Сезне, Равил әфәнде. Сәламәт булыгыз.*

Интервью алучы – Әлифел Таразова 1998

**Вәисиләр тарихын өйрәнәбез**
**( Мулла Иле – изге җир)**

Бөтен гомеремне туган җиремә, туган мәктәбемә багышлаган кешемен. Авылымда 35 ел татар теле һәм әдәбияты укыттым, шуның 26 елын мәктәп директоры булып эшләдем. Шуңа күрә укыту-тәрбия эшен җирле материаллар белән бәйләп алып баруым – бик табигый, дип уйлыйм. 1990 елда республика күләмендә 750 «яше» зурлап үткәрелгән чал тарихлы авылым – Мулла Иле җирле материалларга, әлбәттә, бик бай. Бу язмамда мин шунда туып үскән мөхтәрәм затлар – аталы-уллы Баһаветдин Вәисов, Гайнан Вәисов, шул уңайдан мәктәптә нинди эшләр алып барылганлыгы хакында сөйләргә телим.

Балаларның танып-белү активлыгын үстерүдә фоторәсемнәр бигрәк тә әһәмиятле. Менә Гайнан Вәисовның Бөтендөнья почта союзы чыгарган открыткадагы фотосурәте (1909). Монысы Сөембикә манарасына ай куючы вәисовчылар (1917, сентябрь). Аның янында Г. Вәисов үтерелгән йорт (Тукай урамы). 1989 ел. Казандагы ял паркында Г. Вәисов каберенә һәйкәл кую күренешләре; атаклы тарихчы А. Халиков һәйкәл өстеннән япманы төшерә; композитор Луиза Батыр-Болгарый чыгыш ясый; һәйкәлне иҗат итүче Таһир Абдуллин фотосурәте; Газизҗан Вәисовның Сталин лагерьларыннан әйләнеп кайткач төшкән рәсеме (1955).

«Вәисовчылар эзеннән» дигән экскурсияләрне балалар аеруча ярата. Г. Вәисов үзенең бөтен хатларында «изге җир», дип атаган Мулла Илендәге экскурсияне аның туган нигезе урыныннан башлыйбыз. Юкәсәр урамын узып авыл башына чыккач, зур-зур карт өянкеләр үскән чокырлы җир бар. Менә шуның янәшәсендәге йортта туган, уйнап үскән алар. Бередә чокырның икенче ягында – Кирәмәт күле дип аталган изге күл бар. Аның янында хәзер дә намаз укыйлар. Вәисовлар да, авылларын сагынып кайткач, изгеләр рухын яд итеп, сәҗдә кылганнар. Күлдән арырак – зират. Анда XV гасырда ук куелган кабер ташлары әле дә бик мәһабәт булып басып тора. Менә кызыл кирпечтән өелгән төрбә. Монда Вәисовлар нәселенең борынгы бабалары күмелгән. Шушы төрбә янына тезләнеп, ата белән ул догалар укыганнар.

Экскурсияне Олы Урамдагы мәчет янында дәвам итәбез. Биредә атаклы мәдрәсә булган. Аның турында К. Насыйри: «Мулла Илендә яхшы укымышлы мөгаллимнәр дәрес әйткән», – дип язып калдырган. Бу мәдрәсәдә үзенең дус мөгаллиме янында Габдулла Тукай да кунак булып киткән (1910). Атаклы Вәисовлар исә менә шушы мәдрәсәдә белем алган. Казанга баргач, без иң элек Сөембикә манарасы янына киләбез. 1918 елның мартында карагруһчылар тарафыннан үтерелгән Г. Вәисов Сөембикә манарасы янына күмелә. Аннары ул Казанда М. Горький исемендәге Үзәк ял паркындагы туганнар зиратына күчерелә. Укучылар әлеге зират белән дә таныша: һ. Такташ, Г. Камал каберләре. Янәшәдә генә Г. Вәисов җирләнгән...

Вәисовлар тормышындагы аеруча кызыклы һәм дулкынландыргыч вакыйгаларны хикәяләп, үзем әзерләгән язмалар буенча изложениеләр яздыру укучыларның танып-белүен үстерүдә аеруча отышлы алым булып тора. Менә аларның кайберләренең исемнәре: «Мулла Иле һәм Толстой», «Мулла Илен Һиндстанда беләләр», «Б. Вәисов Академиясе», «Ясная Полянада». Эпиграфны Б. Вәисов шигырьләреннән сайлап алырга кушам. Хатлардан, көндәлекләрдән өзекләр алу, хәзерге көн өчен аеруча аваздаш булган цитаталарны яздыруга игътибар бирәм. Мәсәлән, Толстойның Сардарга язылган хатында мондый юллар бар: «Киләчәктә барлык халыклар, нинди милләт булуларына карамастан, үзара туганнар кебек яшәрләр».

Изложение өчен планны үзем бирәм. Бу вакытны әрәм үткәрмәскә, төп фикерләрне төшереп калдырмаска ярдәм итә. Иллюстрацияләр дә файдаланам.

Әдәбият түгәрәгендә шагыйрь Баһаветдин Вәисовның шигъри осталыгы серләрен өйрәнәбез. Канатлы юлларны дәфтәрләргә матур итеп гарәп хәрефләре белән дә язабыз.

Бәрәкәтләр иңеп һәр кешегә,
Хөрлек тулсын иде җиһанга.

Бу Б.Вәисовның 1874 елда язылган шигыреннән бер өзек. Иң зур әсәре 250 строфадан тора. Ул «Төрле җинаять һәм афәтләрдән саклаучы дога» дип атала.

1874 елда Б. Вәисовның Казанда ике китабы басылып чыга. Шигырьләре ирекле үлчәмдәге алты юллы строфалардан тора. Бу – ул дәвердәге татар шигырь төзелешендә яңалык булып исәпләнә.

«Вәисиләр һәм Толстой» дигән темага рәсемле журнал чыгарабыз. Монда без Толстойның, Вәисовның рәсемнәрен файдаланабыз. 1909 елның февралендә Сардар Вәисов Ясная Полянага килә һәм Толстой янында өч көн кунак була. Толстой көндәлегеннән юллар: «Кичен Вәисов килде... Ул матур, тыныч йөзле, матур тешле, кара сакаллы, күзлекле, ак чырайлы, гади, тыйнак Казан татары». Толстой Сардарга Казан турында сөйли, чөнки ул яшьлегендә университетның Көнчыгыш факультетында укыган. Сардар Толстойның Коръәнне яхшы белүенә таң кала. Казанга киткәндә, Толстой: «Колач җәегез, үсегез, чәчәк атыгыз», – дип озатып кала.

Карагруһчылар Мөселман академиясенә һөҗүм итә. Сардар, кулга алынгач, үзен төрмәдән коткару өчен ярдәм сорап, тагын мәрхәмәтле Толстойга хат яза. Тиз арада Толстойдан аңарга 3 мең сум акча килеп төшә. Сардарга суд башлана. Толстой судның нәтиҗәләре белән кызыксынып тора, ләкин хөкем карары бөек язучының үләренә берничә көн кала гына чыга.

Укучылар белән Вәисиләр шәҗәрәсен өйрәнү буенча да эзләнү эшләре алып барабыз. Вәисовлар үзләрен Мөхәммәд пәйгамбәр нәселеннән дип санаганнар. Төрле дәвердә бу нәселдә Мөхәммәд пәйгамбәр рухындагы остазлар туып торыр, болар динне һәм әхлакны төзәтергә хезмәт итәрләр. Гайнан Вәисов – шул нәселнең 32 нче буыны. Шәҗәрәләр арасында иң тулысы – Сардар кызы Һаҗәр Вәисова төзегән шәҗәрә.

Мин Сардарның улы Мидхәт абый Вәисов белән студент елларында ук яхшы таныш идем. Ул Мәскәүдә халыкара элемтәләр институтында өлкән фәнни хезмәткәр булып эшли, икътисад фәннәре кандидаты иде. Авылга еш кайтып йөрде. Әтисе турындагы дөреслекне дөньяга игълан итү өчен, Казандагы күпме бусагаларны таптады ул. Безнең укучылар алдында да кызыклы чыгышлар ясады. (Мәктәпкә оныгы Наиләне дә алып килә иде.) Төрле илләр икътисады турында язган калын-калын китаплары Мәскәүдә басылып чыкты. Мидхәт абый 1986 елда вафат булды. Хатыны М. Б. Вәисова Мәскәүдә мәктәп директоры булып эшләде. Безнең авылга хәзер дә кайтып йөри. Аның белән хат алышабыз. Мәктәптә Гайнан Вәисовның хатларын укып өйрәнәбез. Аның Мулла Иленә иксез-чиксез мәхәббәтен күреп сокланабыз.

Мулла Иле урта мәктәбен тәмамлап, байтак кына укучылар татар филологиясе факультетында укыдылар һәм мәктәптә үк өйрәнә башлаган җирле материалларга нигезләнеп курс-диплом эшләре яздылар. «Мулла Иле тарихы» (Рөстәм Сәйфетдинов), «Тел галиме Г. Саттаров» (Равилә Сәйфетдинова), «Мулла Иле авылының ономастикасы» (Ф. Сафина) һ. б. диплом эшләрен, алардагы Вәисиләр турындагы фикерләрне дәресләрдә кычкырып укыйбыз.

Авыл тарихы музеенда экскурсовод укучылар Вәисиләр турында кызыклы һәм мавыктыргыч итеп сөйли.

Бүгенге көнне Мулла Илендә яшәүче Вәисиләр нәселенең иң күренеклесе – Гомәр абый Гайфиев. Ул үзенең тормыш иптәше Таибә апа белән мәктәптә еш була. Илнең төрле почмакларында яшәүче вәисовчылар турында кызыклы итеп сөйли. Алар ел да икәүләп март аенда Сөембикә манарасы янына – Сардарны искә алу тантанасына баралар, намаз укыйлар.

IX һәм X сыйныфларда әдәбият һәм тарих дәресләрен берләштереп тә үткәрәбез.

Б. Вәисов XIX гасырның 60 нчы елларында Ислам динен сафландыру максаты белән хәрәкәт башлап җибәрә. Байлар һәм ярлыларга бүленмәгән гадел җәмгыять төзү вәисовчыларның изге максаты була. Ләкин мондый хәрәкәт патша хакимиятен борчуга сала, шуның өчен аларны Себергә сөрәләр. Б.Вәисов исә 1884 елда сәламәт килеш юләрләр йортына ябыла һәм анда ун ел буе интектерелә.

1917 елдан соң Г. Вәисов үз хәрәкәтен большевиклар белән якынлаштыра. Ләкин бу ясалма берләшү була. Чөнки большевиклар эшчеләр сыйныфын бәхетле итүне максат итсәләр, вәисовчылар барлык кешеләрне дә «бертуганнар» итеп күрергә телиләр. Алар Мөселман яшел гвардиясе төзиләр. Ләкин Г. Вәисов 1918 елда һәлак ителә. Җитәкчелек аның энесе Газизҗан Вәисов кулына күчә. 1921 елда большевиклар вәисовчылар оешмасын тулысынча юк итәләр.

1996

**Яшел Үзәндә – Тукай эзләре**

Олуг шагыйрьнең эзләрен Яшел Үзән төбәкләре дә кадерләп саклый. Безнең Мулла Иле авылы Габдулла Тукайның үзен күреп белә. 1910 елның җәендә аны авылыбызга кунакка мәктәбебез укытучысы Гыйззәтулла Акбиров алып кайткан. Әлеге мөгаллим Казанда Татар укытучылар мәктәбендә укыган һәм шул елларда Тукай белән якыннан танышкан. 1906 елда Россия хөкүмәте барлык татар авылларында башлангыч күләмдә мәҗбүри рус телен укытуны кертә һәм Мулла Илендә, Зөя өязендә беренче булып, рус теле укытыла башлый. Г. Акбиров бу эшне башлап җибәрүче талантлы педагог була. Габдулла Тукай дин сабагы укытыла торган мәдрәсә белән янәшә рус теле өйрәнелә торган мәктәптәге укыту эшләре белән бик кызыксынып таныша. Мәктәп бинасы эчендә укытучының яши торган бүлмәсе дә була. Тукай шул бүлмәдә кич кунган һәм үзенең сәер гадәте буенча стенага шигырь дә язып калдырган. Шагыйрь мәдрәсә янындагы мәһабәт мәчеткә карап гыйбадәт кылган. 1898 елда салынган, бөек Тукайның үзен күреп белгән бу мәчетебез хәзер дә исән-сау, бөтен авылыбызга иман нуры таратып эшләвен дәвам итә. Авылга Тукай килеп кергән урам хәзер дә Кала капкасы урамы дип атала, Тукай йөргән иң озын урам Тукай исемен йөртә. Тукай урамы белән параллель рәвештә Вәисиләр урамы сузыла. Бөек шагыйрь бу урамда да йөргән һәм Вәисиләр яшәгән урында тукталып уйланып торган. 1908 елда иҗат иткән "Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш" поэмасында ул бит менә шушы Вәисиләр – Мулла Илендә туып үскән аталы-уллы Баһаветдин һәм Гайнан Вәисовлар (милли азатлык хәрәкәтенең күренекле

җитәкчеләре) турында да язган. (Якташыбыз, профессор Рәмзи Вәлиев (Карашәмдә туган) үзенең хезмәтләрендә Тукайның Вәисиләргә карашының үзгәргәнлеген исбат итте).

Тукай, Мулла Илендә алган тәэсирләреннән чыгып, мондый шигырь юлларын иҗат иткән:

*Читтәге бик күп өяздә, күр, авыллар яктыра,*
*Пар, тату йолдыз кеби, школ белән мәктәп тора.*
*Бу ике дус, берсенә чөнки аларның берсе тиң,*
*Бертигез тәгълимнәре дә: берсе – дөнья, берсе – дин.*
(Г.Тукай. Әсәрләр, 1968, 337 нче бит).

Бәчек авылында Тукайның сөекле апасы Бибисаҗидә Зиннәтулла кызы Хәбибуллина (1877 -1956) яшәгән, аның кызы Өммөһания Әхмәтсафа кызы Хәбибуллина (1903 - 1975) Бәчектә мәктәп директоры булып эшләгән. (Өммеһания белән бергә укыткан Суфия Шакирова, Рәхилә Харисовалар гүзәл истәлекләр сөйлиләр иде), Бәчек зиратында аларның каберләре мәңгеләштерелгән (Бу эштә Тукай исемендәге колхоз җитәкчесе Әмир Фәсхетдинов, авыл Советы рәисе Наил Гатауллин һәм, әлбәттә, мәдәният бүлеге мөдире Әслах Баязитов башлап йөргәннәр иде).

Бәчектә һәр апрель саен район һәм республика шагыйрьләре катнашында зур поэзия бәйрәме – Тукай бәйрәме үткәрелә. Якташыбыз, артист Рәшит Сабиров (Бәчектә туган) Тукай шигырьләрен аерым бер җылылык белән башкара, чөнки ул бит Бибисаҗидә турындагы кадерле ядкарьләрне тыңлап үскән.

Тукай премиясе лауреатлары арасында безнең якташларыбыз да булу белән горурланабыз. Менә алар:

Мәхмүт Хәсәнов (1927-1990, гомере буе безнең шәһәрдә яшәде) – "Язгы аҗаган" романы өчен.

Режиссёр Гали Хөсәенов (1919 елда Күгәйдә туган) – Т.Миңнуллинның "Ай булмаса, йолдыз бар" пьесасын сәхнәгә куйган өчен.

Сара Садыйкова (1906-1986), (аның бабасы Садыйк Айдар авылында яшәгән, кабере дә шунда, ире Газиз Айдарский – шушы авылныкы) – популяр җырлар иҗат иткән өчен.

Фаил Шәфигуллин (1939-1982), (Карашәмдә туган) 1982 елда Тукай премиясенә тәкъдим ителгән иде, ләкин шул елны шагыйрь һәлак булгач, премия бирелми калды.

Гомере буе Яшел Үзән шәһәрендә яшәгән тел галиме Шәриф Сайкин Тукай иҗатын мәктәптә укыту методикасын бастырып чыгарды (1957 елда). Мин гомерем буе мәктәптә Тукайны шуның буенча укыттым.

Академик һәм профессор Гомәр Саттаров (Мулла Илендә туган) Казан университетында укыган елларда (1950-1955) Габдулла Тукай исемендәге стипендиягә лаек була. Гомәр Саттаров үзенең әсәрләрендә Тукай турында мондый юллар язган:

*Күк йөзендә якты исемнәр күп,*
*Иң яктысы шуның нурлы ай.*
*Җирдә балкып янган шагыйрьләр күп,*
*Айга тиңе шуның бер Тукай*
*Хаклык өчен, Тукай кебек, җаным аттым,*
*Тугры, хак сүзлене үз иттем, яраттым.*

Якташыбыз, Танайда туып үскән күренекле язучы Афзал Шамов (1901-1990) 1958 елда Казанда Габдулла Тукай һәйкәлен ачты (ул Язучылар союзы рәисе иде) һәм болай диде: "Тукай татар халкының әдәбиятын үстерүдә онытылмас эш эшләде. Ул – гасырлар шагыйре, халык шагыйре". (Ул чакта мин студент идем). Яшь шагыйрә Рамилә Майорова Афзал Шамов исемендәге премия белән бүләкләнде (шәкертем).

Бөек Тукай шигырьләрен рус теленә гаҗәеп зур осталык белән тәрҗемә иткән һәм иң атаклы рус шагыйрьләренең югары бәясен алган кеше – Вил Ганиев (1934-2005). Вил Ганиев – Норлат авылында туган, Норлат урта мәктәбен бетергән, аннары гомере буе Мәскәүдә әдәбият галиме булып эшләгән һәм үзе дә талантлы шагыйрь һәм язучы. Аның тормыш иптәше – шагыйрь Әхмәт Ерикәй кызы.

Вил Ганиевнең әнисе Сания апа (1910-1980) гомере буе Норлат урта мәктәбендә татар әдәбиятын укытты, Россиянең атказанган укытучысы исеменә лаек булды. Тукай иҗатын мәктәптә укыту турында бик күп хезмәтләр бастырды. Ул – Гомәр Саттаровның укытучысы. Мине дә VIII-X классларда әдәбияттан Сания апа укытты. 1956 елның 26 апрелендә Норлат мәктәбендә Тукайның 70 еллык юбилеен ничек үткәргәнебез бүгенгедәй хәтеремдә. Ап-аяз көн, шундый җылы, рәхәт. 1100 укучы (ул вакытта балалар шундый күп иде) мәктәп ишек алдындагы зур мәйданга яшел чирәм өстенә тезелеп утырганнар. Сания апа Тукай турында йөрәкләргә үткәзеп сөйли. Сания апа миңа да сүз бирде. Мин бик тә дулкынланып, үземнең Тукайга багышлап язган шигырьне укыдым. Бик тә озын килеп чыккан шигырьдәге бу юллар әле дә исемдә:

*Бигрәкләр дә иртә киттең, шагыйрь,*
*Яшьтәшләрең әле исәннәр.*
*Хыялларың чынга ашкан чорда*
*Синең өчен алар яшәрләр.*

Шул елның көзендә инде мин Казан университеты студенты идем. Мин Казанда Габдулла Тукай яшәгән "Болгар" кунакханәсе янындагы йортта яши башладым, һәр көнне Тукай торган йорт тәрәзәләренә карап узып китә идем.

**Гомәрле халык – гомерле халык**

Мәктәптә татар телен укыту программасында берничә күренекле галим-филогогның иҗатын өйрәнү дә каралган. Алар арасында бөтен гомерен татар ономастикасын өйрәнүгә багышланган һәм бу өлкәдә фундаменталь хезмәтләр язган галим, профессор, академик, Татарстан һәм Россиянең атказанган фән хезмәткәре Гомәр Саттаров-Мулилле дә бар. Аның биографиясе һәм фәнни эшчәнлеге дә портреты белән бергә XI сыйныф өчен татар теле дәреслегендә урын алган. Быел да мин XI сыйныфта аңа багышланган дәресләрне аерым бер рухлану белән укыттым. Гомәр Саттаров үзебезнеке бит, безнең авылдан, ул да безнең мәктәпне тәмамлаган, шуның өстенә ул – минем ут күршем дә, аннан соң әле мин үзем дә аның эзеннән барган кеше: мин дә аның кебек Норлат урта мәктәбен, Казан университетын тәмамладым, аннан соң гомер буе татар телен укыттым. Быел да укучыларым, Гомәр Саттаров турында материаллар туплап, кызыклы сочинениеләр яздылар. Аларның

берничәсенең әби-бабасы Саттаров белән мәктәптә бергә, хәтта бер сыйныфта укыганнар икән. Шул кадерле истәлекләрне туплау һәм сыйныфта бергә-бергә кычкырып уку бик тә тәэсирле, дулкынландыргыч булды.

Гомәр абый миңа яңа чыккан һәр китабын чын күңеленнән бүләк итә. Менә беренче басылып чыккан китабы – "Мәктәптә тел культурасы" (1965). Бу китапны мин дәресләремдә 40 ел кулландым, әле хәзер дә кулдан төшермим. Бу китапта безнең якта кулланыла торган диалекталь (җирле) сүзләр тикшерелгән, автор әдәби сөйләмгә ия булу юлларын өйрәткән. Иң мөһиме шунда: җирле сүзләрне яхшы белергә кирәк, алар да бит безнең олы хәзинәбез, алар да тора-бара әдәбиләшеп китә ич.

Айравык, кәлтә, беравык, былчырак һ.б. сүзләр 40 ел эчендә әдәби әсәрләргә дә барып керделәр бит. Галим моны яшь чакта ук сиземләгән. Менә "Мәктәптә туган як ономастикасы" дигән китабы (1984). Монда инде Мулла Иленең бөтен тарихы урын алган, монда безнең төбәктәге һәр күл, елга, чокыр, тау, ерым исемнәренең килеп чыгышы тикшерелгән. Туган якка, туган халыкка мәхәббәт тәрбияләүдә бу хезмәтнең әһәмияте гаять зур. Әгәр дә соңгы 50 ел эчендә Мулла Иленнән 50 кеше татар филологиясе факультетларын тәмамлаган икән, монда Г.Ф.Саттаровның өлеше бик күп. Галим аларның күбесенең диплом эшенә җитәкчелек итте (Фирдәүсә Кәримова "Мулла Иленең тарихы һәм топонимикасы" дигән темага, хәзер Мулла Иле авылы Советы рәисе Илдар Сәлахиев "Мулла Иле төбәгенең антропонимикасы" дигән темага, Равилә Сәйфетдинова "Профессор Г.Ф.Саттаровның фәнни-педагогик эшчәнлеге" дигән темага диплом эшләре яздылар).

Менә "Татар антропонимикасы" дигән фундаменталь китабы (1990). Биредә татар исемнәре, кушаматлары ерак тарихтан башлап җентекләп тикшерелгән, бик күп телләр белән чагыштырылган. Исемнәр, кушаматлар – алар гади атамалар гына түгел, алар тарихны белергә ярдәм итә торган ядкарьләр, шаһитлар икән. Бу китапта минем нәселем йөртә торган кушамат та анализланган. Минем "дардуш" дигән кушаматым атамасы моннан 1300 ел элек (VII гасырда) әллә кайдагы Енисей, Орхун дигән елгалар буенда борынгы бабаларыбыз балбалларга язып куйган ташъязмаларда да очрый икән. Бактың исә, мин VII гасырда яшәгән бер төрки кабиләнең исемен йөртәм икән ич.

Безнең авылда кушаматсыз кеше юк, диярлек. Һәрберсе – үзе бер тарих. Менә – "дарана" кушаматы. Бу атама скифларның варислары булган осетин халкы телендә "көтү тупламы" дигән мәгънәдә икән. Бу нәсел кешеләре бик зур бәдәнле, әзмәвердәй затлар. Димәк, нәселыруны туплаучы башлык булган алар. Менә – "Эшкә" кушаматы. Бу гарәп сүзе "эшкар"дан ясалган ("җирән чәчле" дигән мәгънәдә). Димәк, авылыбызда гарәпләр дә төпләнеп калган икән.

Мулла Иле XIII гасыр уртасында нигезләнгән. Аңа чаклы биредә мари-удмурд халыклары да яшәгән. Бу халыкларның сүзләре әле хәзер дә бездә күп саклана. Зөянең бер ермагы Чиркәлше ("кәкре елга" мәгънәсендә – марича). Кухмар күле ("тирән" мәгънәсендә – марича). Мөңгер инеше (мөңгер – марича "кизләү, инеш, елгачык" мәгънәсендә).

Безнең авылда Әрә атамасы аеруча киң таралган 1. Әрә – Зөя елгасының шактый гына зур кушылдыгы; 2. Әрә эче – безнең авыл

уртасыннан буйдан-буйга ике чакрымга сузылган уйсулык, аннан язгы сулар ага, электә ул елга булган, авыл шул елга буена корылган; 3. Үле Әрә – моннан еракка сузылган печәнлек, көтүлек, тоташ уйсулыктан тора, элек ул елга булган, хәзер кипкән, дөрес, язларын диңгез кебек тора.

Әрә атамасының этимологиясе кызыклы. Ул мордва телендәге "ра" сүзеннән алынган булса кирәк ("ра" – мордва телендә "су" мәгънәсендә). Хәер, борынгы чорда Иделне дә Ра дип атаганнар.

Кеше кушаматлары күп нәрсә сөйли. Пускар кушаматы (удмурдча – "оя"), Ызай кушаматы (удмурдча "таш"), Канак кушаматы (болгар бабайларча "каймак"), Матур кушаматы (чуашча "чикләвек"), Күлүч, Карсак, Чулак кушаматлары (борынгы төрки телдәгечә "данлы", "дала төлкесе", "вак балык") – болар барысы да ерак тарихыбыз авазлары булып торалар.

"Татар топонимикасы" китабында (1998) бөтен дөньяга таралып утырган Татар иле картасындагы атамалар белән танышабыз. Аларның күплеге һәм күптөслелеге, шуларны Г.Саттаровның ничек җыеп бетергәнлеге хәйран калдыра.

"Атамалар дөньясына сәяхәт" (1992) дигән китапны укучылар әдәби әсәр кебек мавыгып укыйлар. Ә инде "Татар исемнәре ни сөйли?" дигән зәңгәр тышлы калын китап (1998) һәркем өчен кадерле. Чөнки кешегә үз исеменнән дә якын, кадерле исем юк. Бу китап кына түгел, бу – исемнәр кануны. Бу – милләтнең яшәеш көзгесе. Бу китап гасыр буе, балалары туган саен, әти-әниләрне сөендереп яшәр дә яшәр әле. Китап белән бергә Гомәр абый да яшәр.

Г.Саттаров олы галим генә түгел, ул тынгысыз җәмәгать эшлеклесе дә, оста оештыручы да. Мулла Иленең 750 еллык юбилеен бөтен республика күләмендә зурлап үткәрүне оештырды ул (1990). Мулла Иле мәктәбенең 100 еллык юбилеен үткәрүдә ничек җиң сызганып йөрде (1990). Аның һәр чыгышы, һәр докладя, һәр лекциясе – үзе бер тамаша. Татарның тел байлыгы хәзинәсе зур кодрәт белән агыла аксакал авызыннан. Милләтебезнең искитмәле чичәне. Ул, бастырып чыгару өчен, "Биш бакча" дип исемләнгән шигырь җыентыгын әзерләп куйган.

1949 елда, Пушкинның 150 еллык юбилеена багышлап, Норлат урта мәктәбендә укыганда язган поэмасы – район газетасы "Ярыш"та басылып, аңа призлы урын биргәннәр һәм Пушкин томнары белән бүләкләгәннәр. Тукай стипендиясенә лаек булып, университетны кызыл диплом белән тәмамлаган шагыйрьнең халкына әйтәсе шигъри сүзе бар, әлбәттә.

Иң беренче чиратта, шагыйрь Тукайны олылый:

*Күктә маяк кебек йолдызлар күп,*
*Иң яктысы ләкин алтын ай.*
*Йолдыз кебек якты шагыйрьләр күп,*
*Айга тиңе шуның бер Тукай.*

Шагыйрьнең зур күләмле "Кыйссаи татар" поэмасы милләтебезгә олы бер мәдхия булып тора.

Тау ягы, Норлат төбәге, Мулла Иле – менә аның шигъри диапазоны. "Мин – Тау ягы бөркете!" – ди шагыйрь. Әйе, тау ягы татарлары – горур татарлар!

*Зәңгәр күгең, әнием күзе төсле,*

*Җылы караш белән иркәли:*
*– Бик сагындым, улым, инде башка*
*Тау ягыңны ташлап китмә, – ди.*
*("Тау ягы")*

*Мин тормышта тугры Тукай булдым,*
*Хагын әйттем һәрчак, турысын.*
*Шуңа җыйдым үземә дошманнарның*
*Вак-төяген, эресен, зурысын.*

Шигырьдән башка тора алмаган, шигырьне һәрвакыт экспромт итеп чыгарып, үзеннән-үзе агылгандай сөйли торган гаҗәеп бу талант иясе бер әсәрендә болай ди:

*Булалсам исем-атамалар атаманы,*
*Юк, кирәкмәстер миңа дөньяның башка даны.*

Башка шагыйрьләр шигырьне башта яза, аннары укый. Ә Гомәр Саттаров башта укый, аннары яза.

2006

## Чын кеше һәм чын язучы

***Кояшларга, йолдызларга үрләмичә,***
***Хезмәт иттең шауламыйча, гөрләмичә,***
***Тирән елга кебек тыныч, горур-сабыр,***
***Куйган көчең бизмән җитмәс зур һәм авыр.***

Ярты гасыр буе мәктәптә әдәбият укыткан бер мөгаллим буларак, язучылар дөньясында ирешелгән казанышлар миңа яхшы билгеле. Шул казанышлар эчендә үзебезнең Азат Вергазовның мәртәбәле урыны бар. Чеховның кат-кат әйтә торган сүзе булган: үз өслүбе (язу рәвеше, стиле) булмаган язучы язучы түгел. Вергазовның үз өслүбе байтак әсәрләрендә ярылып ята, укучыны әсир итә. Тормышны тасвирлаганда, сурәтләгәндә үзе генә тапкан буяуларны ничек оста итеп әсәр тукымасына сала белә ул. Әйе, ул тумыштан килгән зур язучылык сәләтенә ия. Шуның белен беррәттән ул, шәхес буларак, чын кеше дә: бу адаштыргыч фани дөньяда пәгамбәрдәй хаклык белән, Толстойдай гел игелек күрсәтеп кенә, барлык тыелганнардан тыелып яши. Мин язучыларның бик күбесен күреп беләм, ләкин чын кеше һәм чын язучы да булганнары бик тә бик аз. Исеме дә Азат булу аңа бик тә туры килгән: ул барлык начарлыклардан да азат. Фамилиясе Вергазов булуда да хикмәт бар: “вергаз” дигән сүз борынгы иран теленнан тәрҗемә иткәндә, “көч-куәт дигәнне аңлата. Язучы кеше буларак та, әдип буларак та соклandыргыч көч-куәткә ия. Вергазов коеп куйган язучы гына тугел, ул оста педагог та, булдырып булмый торганны булдырган мәктәп директоры да, республика телевидениесендә әдәби тапшырулар редакторы булып озак еллар эшләү дәверендә халык йөрәгенә юл тапкан житәкче дә, туксанынчы еллар башында Яшел Үзән шәһәрендә журнал хәтле журнал чыгара алган мөхәррир дә... “Аҗаган” журналының беренче санына (1991*)* сүз башында Вергазов болай ди: “Юлчыга юлдаш кирәк. Яхшы, күңелгә якын, дустанә сүз катардай, каткан күңелләреңне эретердәй, адашканда гына тугел, сәфәр башында ук юл күрсәтердәй, егылганда тартып торгызырдай дус кирәк”. Әдәби әсәр әнә шундый дус булырга тиеш дип саный Вергазов. Бу – аның төп

мәсләге, төп идеясе. Аҗаган образына язучы яшәү мәгънәсен салган: “Төн. Күзеңә китереп төртсәләр дә күрә алмастай дөм караңгы.. Шулчак ерактагы офыкта, һич көтмәгәндә, аҗаган арыш камчылый башлый. Аяк астындагы барыр юлың яктырып киткәндәй була. Талгын җил колак яфракларына кагылып уза. Борынны арышның балавызланып өлгереп килә торган вакытына гына хас хуш исе кытыклый. Аһ, ул мизгел! Аны бернигә дә – алтынга да, зиннәтле асылташларга да алыштырып булмый. Аҗаган еш уйнаган елны арыш башаклары саллы булып өлгерә. Димәк, ипи була. Кара икмәк! Арыш икмәге!”

Вергазов – кечкенәдән үк шигырь җене кагылган бик самими шагыйрь. Кечкенә чакта ук ул Ватан сугышы кырларында ут эчендә йөргән газиз әтисенә хатларын шигырь белән язган. Үзенең беренче шигырь жыентыгына юлламада автор болай ди: “Кеше йөрмәгән сукмаклардан йөрергә яратам”. 1993 елда чыгарган “Язгы сөйләшү” исемле сайланма шигырьләре китабында әнә шул сукмаклар хикмәти буяуларда кешегә ачыла.

Азат Вергазов – прозада зигзаглы сюжетлар, әдәби портретлар, бары тик үзенчә генә булган пейзажлар остасы. Аның төп чәчмә әсәрләре: “Дулкыннар ни сөйли?”, “ Ташу”, “Уяну”, “Авырткан башка тимер тарак”, “Хыялый Хәяли”, “Без – сезнең балалар”, “Йөрәк жыр сорый” повестьлары, “Кайту” романы. Хикәя һәм мәсәл жанрларында да язучының күркәм уңышлары аз түгел.

Вергазов әсәрләрендә моңсу романтика белән үткен сатира һәм яздай ягымлы юмор бергә кушылып бара. Аның әсәрләре дә үзе кебек: тыштан кырыс, ә эчендә шау чәчәкле көләч бакча, тыштан басынкы, ә эчендә арысланнар йоклап ята, җигүле пар атлар тупырдый. Вергазов – сүзне туп-туры әйтә ала торган гаярь кеше.

...Бер елны, чәчәкле май аенда, Карахуҗа урта мәктәбендә районыбыз педагоглары өчен Азат Вергазов иҗатына багышланган үзенә бер төрле кызыклы семинар булды. Әлеге мәктәпнең талантлы укытучысы Әлфия Минһаҗева ачык дәрес үткәрде. 9 нчы сыйныфта 19 укучы утыра. Артта безнең белән бергә Азат Вергазов дәрес тыңлый. Алда – аның әсәрләреннән зур витрина. Бер китабының исеме аеруча кызык: “Кода, май кап!” Бу – язучының хикәяләр китабы... Укытучы Вергазов әсәрләре дөньясында судагы балык кебек йөзә. Укучылар да матур, образлы, сәнгатьле итеп сөйлиләр. Дәрес бик уйлап әзерләнгән, ул укучылар күңелендә гомерлеккә калачак. Дәреснең үзәгендә – Вергазовның “Йөрәк жыр сорый” повесте. Дәрестә “жылы сүз”, “наз”, “ягымлы караш”, “кешелеклелек”, “мәрхәмәтлелек”, “ихтирам”, “хөрмәт”, “игелеклелек” дигән төшенчәләрнең эчке мәгънәләре повесть материаллары нигезендә йөрәккә үтәрлек итеп ачылды. Укучылар әсәрнең тәэсир итү көче турында үз фикерләрен кыю әйттеләр. Повестьта кулланылган риваятьләрнең, әкиятләрнең күчермә мәгънәләрен матур итеп аңлатып күрсәттеләр. Дәрестән соң Вергазов әсәрләренә багышланган конференция булды. Язучы күп санлы педагогларга һәм укучыларга үз әсәрләренең нинди вакыйгалардан алынып язылуы турында тәфсилләп сөйләде, Бу яклар аңа чиксез кадерле. Бу мәктәптә ул тарих һәм география укытучысы булып

эшләгән. Күршедәге Олы Яке мәктәбендә озак еллар мәктәп директоры булган. Бу якларны ул биш бармагы кебек белә, шуңа күрә дә аның геройларының прототиплары нәкъ менә шушы төбәктән. Язучы үзенең балалар тәрбияләү практикасыннан кызыклы эпизодлар сөйләде. Ул эшләгән чакларда бу мәктәптә бик тәртипсез малай була. Берәү дә аны акылга утыртырга ачкыч таба алмый. Азат Вергазов исә ошбу хулиганның беркемгә дә күрсәтмичә көй язганын күреп кала. Менә шул күрүдән башланып китә дә инде дуслык. Аның көенә шагыйрь Вергазов сүзләр яза. Аннары чын педагог аны композитор Арыслан Батыршин белән таныштыра.

Мин Азат Вергазовның барлыгына – миннән бик якында гына яшәп ятуына сөенеп яшим. Мин аның белән беренче тапкыр Казанда радио бинасында таныштым. Алтмышынчы еллар башы иде. Шигырь язучыларны радиодан үз әсәрләрен укыр өчен чакырганнар иде. Вергазов та, мин дә радиодан бик дулкынланып үзебезнең шигырьләребезне укыдык. Әле укытыр алдыннан безгә кат-кат репетиция ясаттылар. Мин шунда шигырьгә гаять бер житдилек белән караучы, шуннан соң гомерлек дустым булып китәчәк бик матур мыеклы бу талантлы шагыйрьгә әллә нинди соклану белән карап торган идем. Шул көннан башлап мин, аның артыннан бер да калмыйча, үзенә күренмичә, бөтен иҗат юлының буеннан-буена ияреп бардым, һәр иҗат җимешен авыз иттем, тын гына сөендем, үзенә сиздермәдем. Ул миңа һәрвакытта бик игьтибарлы булды.

Үземнең дәресләремдә, бигрәк тә 10-11 нче сыйныфларда, Азат Вергазов әсәрләрен өйрәнүне үземнең намус эшем итеп санадым. Яшүсмерләр тормышын, мәктәп дөньясын аның кебек белеп язган әдипләр бик аз. Аның бер әсәрен урта мәктәп программасына керткәндә нинди яхшы булыр иде. Әдәбият укытуда безгә нәкь менә укучыларның үзләре турында язылган кызыклы әсәрләр җитешми.

2007

**Истәлекләр**

**Казанда әдәби түгәрәктә**

1956-1961 нче елларда, Казан университетында укып йөргән чагымда, Бауман урамындагы матбугат йорты минем өчен илаһи бер изге урынга әверелгән иде. Бу мәһабәт бинаның биек вә калын ишекләрен ачып кергәндә миңа бик тә рәхәт иде. Монда тулы хөрлек: сакчы да юк, теләсә кемгә керергә ярый. Өстәге катларга менә торган баскычлар шундый иркен, шундый киң, хәтта филне дә рәхәтләнеп алып менрәлек. Икенче катта “Татарстан яшьләре” газетасы редакциясе урнашкан, менә шунда әдәбият түгәрәге эшли. Мин һәр җомга кичендә, кичке сәгать бишләрдә, әллә нинди ашкыну белән чираттагы җыенга килеп җитәм.

Шактый зур гына булган бүлмә бик тиз арада минем кебек әдәбият җене кагылганнар белән шыплап тула. Түр башындагы өстәл артында җитәкчебез Шәрәф Мөдәррис утыра. Ул минем өчен шундый якын бер кешегә әверелгән иде ки, сугыштан исән-сау әйләнеп кайткан гаҗәеп садә бу зат һәлак булып калган әтиемне хәтерләтеп тора иде.

Ул да сугышны, әти шикелле, Белоруссия чигендә Армиядә хезмәт иткәндә һич көтмәгәндә кинәттән каршы ала. Коточкыч газаплар

кичерә, авыр яралана. Төзәлеп тә бетмәс борын яңадан сугышка китә, Казанга 1946 нчы елда гына әйләнеп кайта. Шагыйрьнең “Тупчы Ваһап” дигән поэмасын әле дә яттан сөйли алам. Ш.Мөдәррис тәрҗемә иткән “Шекспир сонеталары” дигән китап хәзер дә мине нәфислеге белән таң калдыра. Шигърияткә фанатикларча бирелгән бу талант иясе безгә үзенең бөтен лабораториясен алып килеп күрсәтеп бетерде. Сигез-тугыз яшендә үк пөхтәләп ясалган кульъязма китапчыкларына тиклем. Бу тынгысыз җан әдәбият түгәрәген шулкадәр кызыклы алып бара иде: ничәмә-ничә язучыларны чакырып, онытылмас очрашулар үткәрә, яңа чыккан китапларга бездән анализ ясата, рецензияләр яздыра, берсеннән-берсе хикмәтле өй эшләре бирә (ул әйткән рифмалар белән шигырь язып килергә, “Яңгыр ява”га синонимнар җыеп килергә һ.б.).

Әдәбият түгәрәге әгъзаларын санап чыгу үзе генә дә күп нәрсә сөйли: Мәхмүт Газизов (пединститут студенты), Тәлгать Галиуллин (университет студенты), Фәрит Юсупов, Миркасыйм Госманов, Нәҗип Мәдьяров, Шамил Маннапов, Вакыйф Нуруллин, Ринат Рәхимов, Әхмәт Рәшитов, Кояш Тимбикова, Нурмөхәммәт Хисамов, Рахмай Хисмәтуллин, Марс Шабаев, Мидхәт Миншин, Әхәт Синугыл, Шәйхи Садретдинов һ.б. Түгәрәктә без бик күп язучылар белән очраштык.

## Очрашу мизгелләре

**Ибраһим Гази**

Ибраһим Гази сөйләгәннәрдән: “Һади Такташны ни өчен халык яратып укый? Чөнки ул шигърияткә көнкүрешне (бытны) кертте. Иң катлаулы фикерләрне, иң югары идеяләрне, көнкүрешнең меңләгән бизәкләренә төреп, гади генә, үтеп барышлый гына, болай гына әйтеп бирә алды. Образ тудырырга өйрәнү – бик кыен эш. Инде син көл җыючы малай турында хикәя язасың икән, малаеңның өс-башы көлләнеп бетсен, хикәядән көл исе аңкып торсын, “көл булмыйча, гөл булып булмый” дигән әйтемнең мәгънәсе килеп чыгарлык булсын.”

**Әмирхан Еники**

1957 елда язучының “Йөрәк сере” повесте басылып чыккан иде. Безгә шул әсәр турында фикерләребезне язып килергә кушылган иде. Язучы безне тып-тын гына, бер дә бүлдермичә тыңлап утырды. Беркемнең дә чыгышын хупламады да, кире дә какмады. “Әле сезнең башыгыз яшь, аңларсыз әле” дип утырган икән, мин моны соңыннан гына аңладым, үзем дә әсәр турында беркатлы фикерләр әйткәнмен ич.

**Әхмәт Ерикәй**

Әхмәт Ерикәй безнең янга бизәнеп килгән иде. Иреннәренә, битенә иннек сөрткән. Шакмаклы костюм кигән. Түбәтәйдән. Ул сөйләгәннәрдән: “Мин шуңа гаҗәпләнәм: татар җыры белән кытай җыры арасында шулкадәр якын охшашлык бар. Каян килә бу моң? Мин ике йөздән артык җыр язган кеше буларак, җырлар тарихы турында күп уйланам. Безнең бөек җырчыбыз Фәхри Насретдинов Кытайга барды бит. Аның концертында Моа Цзе-Дун үзе утырган. Концерт беткәч, Фәхрине кабул иткән, аркасыннан сөеп: “Хорошо поешь”, – дигән.

**Гөлшат Зәйнашева**

Тукай клубында сәхнәдән үзешчәннәр аның скетчларын уйнап күрсәттеләр. Шул көнне кемдер үзара сөйләшкәндә әйтеп куйды:

“Егетләр салды шобага

Гөлсем Зәйнашевага".

Әйе, бездән шактый өлкән булган бу кызга без сокланып карый идек.

Әдәби-иҗат түгәрәге үзебезнең университетта да эшли иде. Аның белән Зәет Мәҗитов җитәкчелек итте. Шушы түгәрәкләр безне зыялы кешеләр итеп тәрбияләделәр.

**Илдар Юзеев**

Түгәрәкләрдә иң еш була торган шагыйрь ул Илдар Юзеев иде. Без, студентлар, аның иҗатына мөкиббән киткән идек, аның "Таныш моңнар" поэмасын яттан беләбез. Илдар Юзеев безнең шигырьләргә бик таләпчән иде. Әгәр шулар арасында образлы юллар тапса, сабыйларча сөенә иде. Хәтерлим: ул, минем шигырь дәфтәрен укып чыккач, берничә юлны яхшыга чыгарган иде.

Бик күп еллар үткәч, "Сабантуй" газетасының 1997 нче елгы 22 нче ноябрь санында шагыйрьнең түбәндәге язмасын укыдым:

*"Таныш булыгыз: Равил Сәйфетдинов.*

*Сезне кем белән таныштырырга икән? 1961 нче елны Казан дәүләт университетын тәмамлаганнан бирле татар теле һәм әдәбиятын укыткан, 1963 нче елдан башлап үзе укып чыккан Мулла Иле урта мәктәбендә берөзлексез директор булып эшләгән Равил Сәйфетдинов беләнме? Андый мөгаллимнәр һәм директорлар белән без еш очрашабыз. Ә менә мөгаллим дә, шагыйрь дә булган сәләтле шәхесләр бик аз.*

*Мин сезне бу юлы Равил Сәйфетдиновның шигырьләре белән таныштырырга уйладым.*

Илдар Юзеев, Татарстан
язучылар берлегенең
шигърият остаханәсе
җитәкчесе."

Каян эзләп тапкандыр, шагыйрь газетаның бөтен бер битен минем шигырьләр белән тутырып чыгарган, рәсемемне дә урнаштырган, хәтта иллюстрацияләр дә ясаткан. Димәк, шагыйрь шул көнгә чаклы мине күңелендә йөрткән. Миңа гел изгелек теләп яшәгән.

**Әнвәр Давыдов**

Беркөнне шагыйрь Әнвәр Давыдов безне Химиклар сараенда үткәрелгән әдәбият кичәсенә алып барды. Без, түгәрәк әгъзалары, сәхнәгә бер-бер артлы чыгып, шигырь укыйбыз. Соңыннан шагыйрь укыган шигырьләргә йомгак рәвешендә чыгыш ясады. Ул минем ике юлны хәтерләп калган икән.

Берсе анод, берсе катод булып,
Ут иреннәр бергә кушылыр.

Халыкка шушы ике юлны укып күрсәтте дә:
– Күрәсезме, иптәшләр, татар шигъриятенә химик шагыйрь килде, – дип көлдереп алды.

Бу шагыйрьне мин бөтен барлыгы белән яраттым. Дөресрәге, шигъриятгәге бу хикмәт иясенә гомерем буена гашыйк булып калдым. Бүген, гомеремнең соңгы баскычында торган көннәремдә, шагыйрьнең хикмәтле юлларын тагын да әсәрләнебрәк укыйм:

Мин диңгез түгел,

Тик шулай да.
Беркөнне мин сездән китәрмен
Мәңгелекнең диңгезенә чыгып...

Хәтерлим: 1962 нче елда, Гали авылында эшләгәндә, алтын көз көнендә, мин нинди ашкыну белән бик ерактагы Камышлы авылына җәяү барган идем. Ләкин бер дә арымаган идем, чөнки мин үземнең сөекле шагыйрем Әнвәр Давыдовны күрергә барган идем. Камышлы бит аның туган авылы. Миңа ул Казаннан кунакка кайткан дигәннәр иде. Әйе, ул чыннан да кайткан булган икән. Ләкин мин барып җиткәндә, бер сәгать элек кенә китеп тә барган иде.

1968 нче елның җәендә Мулла Иленнән Казанга баргач та, шагыйрь белән очраша алмадым. Бу юлы "мәңгелекнең диңгезенә чыгып киткән" иде.

Мин һәр көнне аны искә алып, аны сагынып утырам.

**Нәкый Исәнбәт**

1960 нчы елның гыйнварендә аның 60 яшьлек юбилее булды. Университетның актлар залында да шул уңайдан бик зур кичә үткәрелде. Мин дә, сәхнәгә күтәрелеп, аңа багышлап язган шигыремне укыдым. Соңыннан әдип, рәхмәт әйтеп, кулымны кысты. Юбилей уңае белән без драматургның "Муса Җәлил" трагедиясен сәхнәләштердек. Кайда гына уйнап күрсәтмәдек ул спектакльне: университет залында да, академия театрында да, Камалов театрында да, Арчага да барып куйдык, әле яңа гына эшли башлаган телевидениедә дә турыдан-туры эфирга чыктык.

**Кави Нәҗми**

Түгәрәк утырышына тиздән Кави Нәҗми килергә тиеш иде. Аның турында күпме белеп тә, әле үзе белән очрашкан юк. Менә очрашыр вакыт килеп тә җитте. Ләкин очрашу насыйп булмады.1957 нче елның 24 нче мартында дәрес вакытында безнең аудиториягә кереп: "Кави Нәҗми вафат" дигән тирән кайгылы хәбәрне ирештерделәр. Аны соңгы юлга озаткан көнне без укымадык. Без дә Камал театры фойесында язучының җәсәде куелган постамент янында сакта тордык һәм күз яше аша барыбызга да рәсемнәре аркылы бик тә таныш, бик тә үз булган мөлаем йөзгә карап бактык. Безнең янәшәдә генә язучының бертуган энесе – шахмат чемпионы Рәшит Нәҗметдинов басып торды. Кави Нәҗмине халык шулкадәр зурлап озатты ки, театрдан алып зиратка чаклы булган барлык урамнар кеше белән тулы иде. Көн җылы, кар эреп бетеп килә. Башларыбызны иеп, әкрен генә атлыйбыз. Юатырга теләп, битләребезгә язгы җилләр кагыла. "Язгы җилләр" романы авторын соңгы юлга озатып барабыз. Әле беркемне бөтен Казан белән озатмаганнар. Чөнки табигатьтә генә түгел, илдә дә җепшеклек хөкем сөрә иде. Демократия җилләре исә иде. Оркестрлар үзәкне өзеп "Тәфтиләү"не, "Тукай маршы"н уйныйлар. Әле бик күп нәрсәне белми идек. Кави Нәҗминең үзенең хатыны Сәрвәр Әдһәмова белән бергә бер гаепсезгә төрмәләрдә интегүләрен әле без бер дә белми идек.

**Шәйхи Маннур**

Өченче класста укыган чагымда минем иң яраткан шагыйрем Шәйхи Маннур иде. Ул иҗат иткән "Миләүшә китабы"н укый-укый, күп кенә шигырьләрен ятлап та бетергән идем. Университетка укырга

кергәч, мин ул Миләүшәне күрдем. Шагыйрьнең кызы Миләүшә белән бер факультетта укыдым.

Шәйхи Маннур безнең белән очрашу кичәсенә 1958 нче елның апреле азагында килде. Искиткеч зыялы, бөтен йөзеннән, чәчләреннән шигъри нурлар бөркелеп торган бу олпат шагыйрь башта тып-тын гына безнең шигырьләребезне тыңлап утырды. Аннары аларга анализ ясарга тотынды. Анализга минем дә “Егерменче язым” дигән шигырем эләкте:

– Бу шигырь тыңлап торырга матур яңгырый. Ләкин бу риторик шигырь, ягъни купшы шигырь. Хәзер мондый шигырьләр чоры узды. Шигырьдә кеше күңеленең яшерен катламнарын ачарга кирәк. Ә синең шигырең, иптәш Сәйфетдинов, коры мактануга корылган.

Аннары язучы әйтә куйды: Мин поездда йөргәндә һаман күзәтәм: халык кырылып китеп укый. Ләкин шигырь китабын түгел, прозаны укый. Мин дә гомерем буе шигырь яздым. Халык мине түгел, Әпсәләмовны укый. Мин дә хәзер проза язачакмын.

Шагыйрь сүзендә торды: “Муса” романын, “Агымсуларга карап”, “Чын сөю бармы?” повестьларын иҗат итте.

Бу очрашуның икенче көнендә “Татарстан яшьләре” газетасының беренче битендә Шәйхи Маннур анализлаган “Егерменче язым” шигыре басылып чыккан иде. Анда мондый юллар бар:

Егерменче язым – чәчәк чагым!
Йөрәк җырлый дәртле көйләргә.
Мин туганмын таза тормыш шавын
Фәрхәд гыйшкы белән сөяргә.

Егерменче язым – чәчәк чагым!
Җитмеш кенә түгел һөнәрем.
Комсомолның корыч ташкынына
Кушылып ага керсез көннәрем.

Ничек кенә булмасын, мин бу юлларны ихластан язган идем.

**Зыя Мансур**

Зыя Мансур белән очрашкач, ул минем шигырьләр дәфтәрен алып калды һәм “Тукай клубына кергәләп тор, мин гел шунда булам”, – диде. Чынлап та, кайчан гына керсәң дә, ул шунда була иде. Әйтерсең, бу – үз йорты.

Кечкенә генә буйлы, шуның өстенә какча һәм арык гәүдәле, ләкин бөтен вөҗүденнән яшерен җылылык бөркелеп торган бу шагыйрь, мине үз янына утыртып, дәфтәрдәге һәр шигырьнең язылу тарихын сораштырырга кереште. Серләремне суырып алганын сизми дә калам. Торган саен, миңа рәхәт була бара.

– Синең шигырьләрең үзенә бертөрле. Менә бу строфаңны укыйк әле:

Мәхәббәтне яулап алу ул
Атакадыр икән белмәдем.
Янып-янып кордым оборона,
Яннарыңа гына килмәдем.

– Атака дисең, оборона дисең. Сугыш нәрсәләре инде болар. Без күрдек шуларны (Аннары шагыйрь сугышта булганнарын искә төшерде). Әле мин уйламаган идем: мәхәббәттә дә оборона һәм атака

бар икән. Син кызык шагыйрь. Һибәтулла Салиховча  да җибәрәсең: “Тәндә җаным  ничә көн миһман икәндер белмәдем”.

Бу строфа коры риторика түгел инде. Монда бер хикмәт бар.

Яшеллек һәм суның арасында
Ныклы союз корган табигать.
Әйдә, без дә икәү шулай булыйк,
Бер-беребезне санлыйк, ниһаять.

– “Ныклы союз” дисең, алайса, ә шигырең барыбер кызык бит чёрт возьми.

Шагыйрь һәр строфаны шулай анализлап чыкты. Һәрберсенә плюс (+) һәм минус (-) билгеләрен куеп чыкты. Ул дәфтәр миндә әле хәзер дә саклана.

**Нәҗип Мәдьяров**

Тормышы шулай килеп чыккан: миннән ун ел олы булса да, Нәҗип Мәдьяров университетка укырга 1957 нче елда килеп керде. Үзенең буй-сыны белән кеше күзенә чагыла торган кеше түгел иде ул. Ләкин шигырьне коеп куя.  Лирика да, юмор да шундый әйбәт килеп чыга.. Үзенең беренче җыентыгын ул тулай торакның “Кызыл почмагы”нда әзерләде. Төннәр буе шунда бөтен идәнгә, бөтен өстәл-урындыкларга кәгазь битләре таратып, җан фәрманга эшли иде. Аның хөрмәтенә без анда керми йөрибез, тынычлап эшләсен, танцылар да булмый тора. Ниһаять, аның беренче җыентыгы – “Чык бөртекләре” (1960) басылып чыкты.

Без Нәҗип Мәдьяровны бик ярата идек. Ләкин ни өчендер “абый” дип түгел “Нәҗип” дип кенә эндәшә идек. Төрле кичәләрдә шигырь сөйләгәннән соң, Нәҗипне алкышларга күмәләр иде. Аның шигырьләре мәкальләр, афоризмнар кебек образлы:

Белем урынына борыныңны
Күтәреп кайта күрмә.

Салкын гына озатып булмый икән
Туган җирнең салкын бозын да.

Югалучан була андый гыйшык
Төштә тапкан акча шикелле.

**Әхмәт Рәшитов**

Әхмәт Рәшитов белән без университетның тулай торагында бер бүлмәдә яшәдек. Аның иң якын дусты Рахмай Хисмәтуллин иде. Физматта укучы бу студент гел безнең бүлмәгә килеп йөри иде. Алар икесе дә баштанаяк романтиклар. Икесенең дә сөйгән мәгъшукалары әдәбият-сәнгать дөньясында танылып килгән затлар иде. Әхмәт шул мәсләгенә гомер буена тугры калды. Сөйгән карчыгы, күренекле язучыбыз Мәдинә Маликова белән бәхетле, озын-озак гомер кичерә. Яшь чакта ук Әхмәт дөнья гизәргә ярата иде һәм үзенең күргәннәрен гаҗәеп образларда сурәтли иде. Шуларның берсе:

Үрелеп җитә алмый ак болыт
Ап-ак бүрек кигән Тянь-Шаньга.

**Мулла Илендә булган һәм халык белән очрашкан әдипләр, галимнәр**

**XIX гасыр азагында:**

1. Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1898). Үзенең якын дусты, Мулла Иле мәчете мулласы Вәлихәйдәр Котлыәхмәтов янына килеп, аңа үзенең кулъязмаларын калдырган.
2. Каюм Насыйри (1825-1902). 1880 нче елда килеп, тикшерүләр алып барып, "Мулла Иле" дигән тарихи хезмәтен язган.
3. Баһаветдин Вәисев (1804-1894). Шагыйрь бездә туган һәм кайтып йөргән.

**XX гасыр башында:**

4. Гайнан Вәисов (1867-1918). 1914 нче елда Мулла Иле кызы Сәйран (Гайнетдин Гайфиев кызы) га өйләнгән. Бөек язучы Лев Толстой аны бик хөрмәт иткән, хәтта үз өенә Ясная Полянага чакырып, өч көн буе кунак иткән, аның аша Мулллла Илен дә белгән.
5. Мидхәт Вәисов (1916-1986). Гайнан белән Сәйранның улы. Мәскәүдә Халыкара элемтәләр институтында эшләгән һәм зур гыйльми хезмәтләр язган. Пенсигә чыккач, Мулла Иленә торырга кайтты. Мәктәп юбилеенда катнашты (1985) һәм гаять кызыклы чыгыш ясады.
6. Габдулла Тукай (1886-1913). Бездә 1910 нчы елның җәендә булган.

**1930 нчы елларда**

7. Һади Такташ (1901-1931). 1930 нчы елда "Кызыл яшьләр" газетасына күмәкләштерү турында хәбәр язу өчен килгән. 1931 нче елда "Чаян" журналында «Мулла Иле булсын да» дигән шигырен бастырган.
8. Халикъ Садри (1890-1955). 1936 нчы елда Мулла Иленә килеп, колхоз тормышын өйрәнә һәм шул турыда шул ук елны "Зыятдин балалары" дигән китабын бастырып чыгара.

**1940 нчы елларда**

9. Мирсәй Әмир (1907-1980). Бездә 1944 нче елда булган һәм "Кызыл Татарстан"газетасында "Кызыл олаулар" дигән мәкаләсен бастырган.
10. Әхмәт Ерикәй (1902-1967). 1946 нчы һәм 1950 нче елларда СССР Верховный Советына депутатлыкка кандидат буларак халык белән очрашуга килде. Бик күп шигырьләрен укыды, артистлар аның сүзләренә язылган җырларын җырладылар.
11. Риза Ишморат (1903-1995). Драматург килгән төшкә авыл үзешчәннәре аның "Кайту" пьесасын сәхнәләштергәннәр иде.
12. Мөхәммәт Садри (1913-1993). 1948 нче елның апрелендә килгән иде. Без, малайлар, кырдан чиләк тутырып, черек бәрәңге җыеп кайта идек. Урамда орден-медальләр таккан гимнастеркалы шагыйрь очрады. Безнең белән туктап сөйләшеп торды, башларыбыздан сыйпады. Кичен шыгрым тулы клубта "Бәхет турында җыр" дигән поэмасын укыды.
13. Гали Хуҗи (1912-1966) 1949 нчы елда килде. Шыгрым тулы клубта "Россия" поэмасын укыды (гимнастеркадан, орден-медальләрен таккан килеш).
14. Салих Баттал (1905-1995). Китапханәдә очучылар турында язган әсәрләре турында сөйләде.

**1950 нче елларда**

15. Сәхаб Урайский (1907-1957). Безнең мәктәпкә 1950 нче елда килде. Залга 500 укучыны җыеп утыртып, үзе әдәби хезәткәр булып эшли торган “Яшь сталинчы” газетасына мәкаләне ничек язарга кирәклеге турында киңәшләр бирде, чөнки без күбебез, беребездән-беребез узышып, хәбәрләр яза идек. Бу шаукым шуннан башланды: 1950 нче елның 12 нче гыйнвар санында әлеге газетада минем “Кышкы каникулда” дигән мәкаләм басылган иде, һәм аның өчен миңа почта белән өч сум акча килде, менә шуннан соң башкалар да язарга тотындылар.

16. Мостафа Ногман (1912-1978). 1953 нче елда шыгрым тулы клубта атаклы төрек шагыйре Назыйм Хикмәтнең шигырьләрен үз тәрҗемәсендә укыды.

17. Афзал Шамов (1900-1990). 1956 нчы елда “Зөя буенда” дигән очеркы өчен материал туплау өчен килгән иде.

**1960-1970 нче елларда**

18. Хәсән Туфан (1900-1981). 1965 нче елның февралендә без шагыйрьне Албаба станиясеннән яхшы ат җигелгән зиннәтле чанага утыртып алып кайттык. Шулкадәр илһамланып, шулкадәр рәхәтләнеп укыды шагыйрь ул төнне үзенең даһи шигырьләрен. Очрашу беткәч тә, Мулла Иленең озын урамнарына сокланып озак йөрде төнге саф тынлыкта.

19. Нәби Дәүли (1910-1989)

20. Роберт Әхмәтҗанов (1935-2008). Кышкы чатырман суыкта аягына туфли киеп килгән иде ул клубка. Аягына киез итекләр китереп кидердем. Без аның белән күптәннән дуслар идек. Мин аның “Гасырлар юлы” дигән китабына рецензия дә язып бастырган идем. Роберт үзенең шигырьләре белән бөтен халыкны әсир итте.

21. Галимҗан Латыйп (1912-1986)

22. Гомәр Саттаров (1932). Мәшһүр галимебез, талантлы нәфис сүз остасы, оста педагог.

23. Рәдиф Гатауллин (1941). Бездә очрашуда булганнан соң, халык аның шигырь укуын бер могҗизага тиңләп сөйләп йөрде, күбесе “Ирләр булыйк” дигән шигырен ятлап та алган һәм җае килгәндә сөйләп тә җибәрәләр иде.

24. Идрис Туктар (1896-1982). Бездәге очрашуда “Ике егет” романы турында сөйләде.

25. Марсель Әхмәтҗанов (1939). Безгә 1972 нче елның көзендә килеп, борынгы китаплар, риваятьләр җыеп йөрде. Еллар үткәч, “Тәмте Хатай” шәҗәрәсен бастырып чыгарды.

26. Мәрзия Фәйзуллина (1930). Клубта балалар өчен язылган шигырьләрен укыды.

27. Габдрахман Минский (1906-1983). Клубта “Мин ни өчен шагыйрь булмадым?” дигән юмористик хикәясен укыды.

28. Юныс Сафиуллин (1947). Артист, драматург. Якташыбыз. Безнең сәхнәдә ул күп мәртәбә уйнады.

**1980 нче елларда**

29. Самат Шакир (1924-?). Клубта һәм мәктәптә үзе эзләп тапкан сугыш геройлары турында сөйләде. Ул да, минем шикелле, укытучы булып эшли иде.

30. Азат Вергазов (1932-1912). Бездә берничә мәртәбә булды. Ул да, минем шикелле, мәктәп директоры һәм укытучы иде.

31. Флюра Гыйззәтуллина (1931). “Шахтадагы атлар” поэмасын укыды.

32. Аяз Гыйлаҗев (1928-2002). Безгә 1988 нче елда хатыны Нәкыя ханым белән килде. (Нәкыя белән без университетта бер группада укыдык. 1957 нче елда аларның туйларын үткәргән идек)

33. Рәшит Гәрәй (1931- 1999). Безгә берничә тапкыр килде. Берсендә каз өмәсендә дә катнашты. (Ул минем шигырьләрьне “Казан утлары”нда бастырып чыгарды).

34. Кави Латыйп (1927-2008). Сугыш ветераны буларак чыгыш ясады.

35. Хәсән Сәрьян (1930-1978). “Әткәм һөнәре” повесте турында сөйләде.

36. Мөсәгыйть Хәбибуллин (1927). “Чоңгыллар” романы турында сөйләде.

37. Мәхмүт Хәсәнов (1927-1990). Берничә мәртәбә килде. Авыл юбилеенда чыгыш ясады. Клубта “Язгы аҗаган” романы буенча китап укучылар конференциясе булды.

38. Мәхмүт Хәсән (1923-1993). Безгә килеп, җәйләүдә терлекчеләр белән очрашты. Зөяне берничә кат аркылы йөзеп чыкты. Иртүк торып, сигез чакрым йөгереп кайтты. Клубта юмористик шигырьләрен сөйләде. (Ул 1960 нчы елда бастырып чыгарган “Чирәм җирләр сулышы” дигән китабында минем турында да очерк язган иде).

39. Мәгъсүм Латыйфуллин. Мәктәптә булып, “Сәйдәшнең балачагы” дигән повесте турында сөйләде.

40. Фаил Шәфигуллин (1939-1982). Клубта һәм мәктәптә булып, ”Чаян” журналы турында сөйләде. Мәшһүр артистыбыз Рәшит Сабиров аның юмористик хикәяләрен сөйләде.

41. Илһам Шакиров (1936). 1987 елның җәендә үзенең төркеме белән бергә Мулла Иле кунакханәсендә берничә атна яшәде һәм бөтен тирә-як авыллардагы кыр станнарында бик күп концертлар бирде. Шул чакта без аның белән бик якыннан аралашып яшәдек.

42. Фәннур Сафин (1948-1992).

**Туксанынчы елларда**

43. Рифгать Кәрами (1942).

44. Салих Маннапов (1953).

45. Вакыйф Нуруллин (1935). “Күпер чыкканда” повесте турында сөйләде. (Аның белән мин университетта бергә укыдым)

46. Кояш Тимбикова (1937-2004). Безгә килеп, “Ярлар биек” дигән повесте турында сөйләде. Кояшның туганы Сәгъдия апа 1940-1960 елларда безнең мәктәптә укытты. Кояш белән без университетта бергә укыдык.

47. Галимҗан Гыйльманов (1957 елда туган). 1999 елның апрелендә булды.

48. Фәүзия Бәйрәмова (1950 елда туган). Безгә килеп, репрессияләнгән укытучы Сәгадәт Мусина турында материал җыйды һәм “Кыңгырау” дигән повестен бастырып чыгарды.

49. Камил Кәримов (1950 елда туган).

50. Эльмира Шәрифуллина (1947 елда туган).

51. Разил Вәлиев (1947 елда туган). Татарстан Югары Советына кандидат буларак, сайлаучылар белән очрашуга килде.

52. Хәйдәр Гайнетдин (1952-2000) Мулла Иле авылына берничә тапкыр килде. 1998 нче елның 12-13 нче октябрь көннәрендә ул, үзенең операторы белән бергә минем 60 еллык юбилеема багышлап, “Замандашыбыз Равил Сәйфетдинов” дигән телевизион очерк әзерләде. Ике көннән соң ук ул эфирга чыкты. Шагыйрьнең тырышлыгы безне гаҗәпкә калдырды. Ул минем биографиямне авыл, мәктәп тарихы белән оста итеп үрә белде. Аның һәр җөмләсендә фактлар калку итеп, образлы итеп, кыска итеп әйтелеп, сурәтләрнең дә иң кызыклылары сайлап алынган иде. Кешеләр тапшыруны бик яратып карады.

Каен урманы уртасында без аны озату кичәсе дә үткәрдек. Көн шундый аяз, җылы, рәхәт иде. Шагыйрь алтын көз кочагында, дулкынланып, шигырьләрен укыды. Аннары, барыбызны да таң калдырып, “Кара урман” җырын җырлады. Гаҗәп көчле, гаҗәп моңлы иде аның тавышы.

53. Гөлзада Сафиуллина һәм Риф Гатауллиннар бездә күп мәртәбә чыгыш ясадылар. Минем сүзләргә алар иҗат иткән “Мулиле” дигән җыр радиодан да бирелде.

54. Тәлгать Галиуллин (1938). Безнең клубта Гомәр Саттаров белән бергә бик кызыклы кичә үткәрделәр. Т.Галиуллин белән мин университетта бер группада укыдым. Тәлгать Галиуллин – чын мәгънәсендә талант иясе, күпкырлы галим, педагог, җитәкче һәм гаять үзенчәлекле язучы.

55. Ренат Харис (1941). “Татарстан хәбәрләре” газетасында баш редактор булып эшләгән чорында безгә килеп, авыл һәм колхоз, мәктәп тормышын, тарихыбызны өйрәнеп, “Мулла Иле – муллык иле” дигән очерк иҗат итте һәм аны 1993 елның 15 октябренда бастырып чыгарды.

56. Альберт Яхин (1931-2010). 1992 елда берничә атна буе безнең мәктәптә университет студентлары белән педагогик практика алып барды.А. Яхин – бәяләп бетергесез новатор галим. Ул әдәбият укыту фәнендә үз мәктәбен булдырды. Яхинча укытучыларның дәресләре берәүне дә битараф калдырмый.

**2000 нче елларда**

57. Сәлисә Гәрәева (1938). Безгә килеп, үзенең шигырьләрен укыды. Без аның белән университетта бер үк елларда укыдык.

*2007 елның декабрендә Мулла Илендә Гомәр Саттаровның 75 яшьлек юбилей кичәсе*

*үткәрелде. Әлеге кичәдә чыгыш ясадылар*: Вахит Хаков, Хатыйп Миңнегулов, Фәһимә Хисамова, Искәндәр Гыйлаҗевлар.

58. Вахит Хаков (1926-2008). Университет профессоры (студент елларымда ул минем диплом эшемнең җитәкчесе иде). Олуг галимебез миңа берничә китабын бүләк итте.

59. Хатыйп Миңнегулов (1939 елда туган). Күренекле әдәбият галиме. (Университетта бер үк елларда укыдык)

60. Фәһимә Хисамова (1936 елда туган). Күренекле тел галимәсе. (Университетта бер үк елларда укыдык).

61. Искәндәр Гыйлаҗев (1958 елда туган). Ул вакытта татфак деканы иде. Аяз Гыйлаҗевның улы.

62. Миркасыйм Госманов (1934-2010). Олуг галимебез бездә 2009 елның 22 сентябрендә хатыны Сәлисә ханым Зәйнулла кызы белән бергә булды. (Без университетта бер үк елларда укыган идек). Ул миңа дүрт китап бүләк итте: өчесе – үзенекеләр, берсе – кызы Диләрә Госманованыкы, ягъни безнең авылдашларыбыз Вәисиләр турында язылган һәм Фәннәр Академиясе тарафыннан басылып чыккан бик күп документларны һәм рәсемнәрне эченә алган 560 битле китап. Профессор Диләрә, Америкадан килгән галимнәрне ияртеп, безнең авылда да тикшерү эшләре алып барды. Аларны үзебез авылдан чыккан фән белгече Камил Шәкуров озатып йөрде.

63. Дания Фәйзуллина – үзебез авылдан чыккан әдибә, хөрмәтле укучым. “Чын мирас” журналы хезмәткәре, “Татарстан язучылары – әдәби премия лауреатлары” дигән китабы 2011 елда дөнья күрде. Мулла Илендә Даниянең туган йорты әдәбият-мәдәният салонын хәтерләтә, чөнки 30-40 елдан бирле авылга килгән зыялылар шушында урнашалар.

64. Роза Хәмидуллина-Гыйззәтуллина. Үзебез авылда туыпүскән әдибә. Мулла Иленә еш кайтып йөри. Мулла Иле халкына “Сиңа илтә юлларым” дигән китабын (2011) бүләк итте.

27 август, 2011 ел

**Тарихларыбыз бергә үрелгән**

**Афәрин, Ирек Сафин! “Туган авылым” дигән әсәрең белән үзеңнең кем булуыңны ачып салдың. Син бит XIX гасырда яшәгән данлыклы сәүдәгәр, халкыбыз өчен биниһая игелекләр эшләп калдырган меценат, Казанның беренче гильдия купецы Мөхәммәтҗан Назир улы Казаков оныгы икәнсең ләбаса!**

Шырдан турында күп яздылар. Ә син исә, шуларны бер дә кабатламыйча, тарихның безгә билгеле булмаган сәхифәләрен шигъри телдә сурәтләп биргәнсең. Үзеңнең легендар бабаң Мөхәммәтҗан Казаковка игелекле эшләре өчен дан җырлыйсың. Әйе, синең бабаң, бөек шәхесебез Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләренең үзеннән фатыйхасын алып, Казанда да, Әстерхан (Хаҗи Тархан) каласында да, Шырданда да, Мулла Илендә дә, тагын әллә кайларда зиннәтле мәчетләр салдырган.

Безнең Мулла Илендәге ул төзеп калдырган мәчеттә 1874-1915 елларда имам-хатыйб булып эшләгән Вәлихәйдәр хәзрәт Котлымөхәммәтов Мәрҗанинең иң якын дусты булган һәм бөек галимнең күп кенә кульязмалары аңарда саклanган.

Мөхтәрәм Мөхәммәтҗан бабаң Мулла Илендә 1873 елда төзеп калдырган мәчет бүген дә халыкка тулы көченә хезмәт итә (138 ел!), без шунда көн дә намаз укыйбыз, мәхәллә тормышы мәсьәләләрен хәл итәбез, борынгы, кабатланмас уникаль бу бинаны халык кадерләп карап, саклап, ремонтлап тора. Аллаһның рәхмәте белән миңа да шушында имам-хатыйб булу насыйп булды.

Казаков дигән фамилиянең кызыклы тарихы бар икән бит: мәшһүр бабаң Кавказ сугышлары чорында патша армиясендәге казакларга йөз баш аргамак юнәтеп биргән! Шуннан сезнең нәселгә әлеге фамилия ябышып калган.

Бактың исә, Ризаэтдин Фәхретдин хәзрәтләренең бабалары да Шырданнан чыккан икән бит. Бу турыда, табигый, аеруча тәэсирләнеп язгансың. Бу урында шуны да әйтеп үтим әле (гел үз тарихыңны кыстырасың димә, чөнки безнең тарихлар бергә үрелеп бара, Яшел Үзән – бербөтен): XVII гасырда Мулла Иленнән 30лап гаилә Чирмешән якларына күченеп киткән була. Шул тарих бүген дә исән икән. Хәзерге Чирмешән районы Туймәт авылы кешесе Локман Сәхапов "Туймәт авылы шәҗәрәсе" дигән китап язып бастырган. Ул һәм Казандагы берничә зыялы зат безнең мәчеткә сәяхәт ясап киттеләр. Әлеге китапны бүләк иттеләр. Иң мөһиме: алар белән бергә килгән галимә Мәдинә Рәхимкулова безгә Р.Фәхретдиннең "Җәвамигуль-кәлим шәрхе" дигән атаклы китабын бүләк итте. Бу китапны басмага галимә үзе әзерләгән, хәзерге телебезгә үзе тәрҗемә кылган. Галимә Чирмешән якларыннан һәм шәҗәрәсе Р.Фәхретдингә тоташа.

Менә нинди бәхет: синең кулыңда бабаңның үз кулы белән гарәп шрифтында язып калдырган китабы саклана икән. Син бит бу хәлне матур итеп шигъри юлларга салгансың. Миндә дә бар андый бер китап (Авылыбыз мулласы Вафа хәзрәт 1928-1935 еллардагы хәлләрне гарәп хәрефләре белән тасвирлап язган кара тышлы кулъязма китап. Бердәнбер китап. Тарихны бөртекләп саклыйк!).

Шырданның атаклы катыгын югары кимәлгә күтәрә алгансың, моны осталыгың итеп бәялисем килә:

Болгар ханы биләмәсе булып,
Күпне күргән Шырдан катыгы.
Шул чаклардан бирле дан казанган
Шәйкәләрдә Шырдан катыгы...
Декабристлар узган бу тирәдән,
Тирә-якка чәчеп моңнарын.
Әби патша түрәләре узган,
Бөек Пушкин узган... һәм тагын
Халык сөйли: "Алар китмәгән бит
Ашамыйча Шырдан катыгын".

(Барыбызга да мәгълүм шәхес Фикрәт Табеевның Шырдан катыгын ничек яратуы турындагы риваятьләрен тыңлап үтте безнең гомер). Шырданның элгәреге бай табигатен, гүзәл кешеләрен ничек өзелеп сагынасың, шуларны кире кайтарырга чакырасың.

Булган бит шундый чаклар:
Сәкел суы, дәрья булып агып,
Әтил суларына кушылган...
Чирмеш суы аккан кизләү булып,
Тал-тирәкләр торган сагында.

(Безнең авылда сусак дигән чәчәк үсә, ул су сагы дигән мәгънәсендәдер).

Карамалы кара урман бүген
Мәңгелеккә китеп югалган.

Әсәрнең бөтен тукымасына эпиграф итеп куярлык строфаны билгеләп үтәсем килә:

Ак таулардан талгын җилләр исә,
Туган ягым Шырдан ягына.
Якты эзләр салган бабайларны
Күңел эзли, күңел сагына.

Түбәндәге юлларың минем дә, барыбызның да иң мөкатдәс уртак теләгебез булып тора:

Гомер уза, аккан сулар сыман,
Тарих дәвам итә бүген дә.
Элеккечә балкып янсын иде
Зур шәхесләр Шырдан күгендә.

Яңадан-яңа образлар, шигъри детальләр, укучыларны сискәндереп җибәрә торган гыйбарәләр эзләп табарга насыйп булсын алдагы иҗатыңда.

2011